**100** лет со дня рождения Вадима Александровича Сивкова (1925–1944)

– Вадим Александрович Сивковның тууына 100 ел (1925–1944)

**110** лет со дня рождения Ильи Ильича Стратейчука (15.05.1915–1995)

– Илья Ильич Стратейчукның тууына 110 ел (15.05.1915–1995)

**110** лет со дня рождения Самуила Михайловича Тапикова (01.11.1915–1945)

– Самуил Михайлович Тапиковның тууына 110 ел (01.11.1915–1945)

**110** лет со дня рождения Сергея Яковлевича Фильченкова (18.03.1915–1965)

– Сергей Яковлевич Фильченковның тууына 110 ел (18.03.1915–1965)

**100** лет со дня рождения Валий Хазиахметовича Хазиева (09.07.1925–1996)

– Вәли Хаҗиәхмәт улы Хаҗиевнең тууына 100 ел (09.07.1925–1996)

**120** лет со дня рождения Мингаса Хайрутдиновича Хайрутдинова (15.08.1905–1970)

– Минһаҗ Хәйретдин улы Хәйретдиновның тууына 120 ел (15.08.1905–1970)

**110** лет со дня рождения Виктора Алексеевича (Валиулла Алиевича) Чалдаева (15.05.1915–1944)

– Вәлиулла Али улы (Виктор Алексеевич) Чалдаевның тууына 110 ел (15.05.1915–1944)

**110** лет со дня рождения Анатолия Алексеевича Чепуренко (1915–1945)

– Анатолий Алексеевич Чепуренконың тууына 110 ел (1915–1945)

**100** лет со дня рождения Николая Григорьевича Чунтонова (22.05.1925–1977)

– Николай Григорьевич Чунтоновның тууына 100 ел (22.05.1925–1977)

**110** лет со дня рождения Гали Нурулловича Шамсутдинова (22.05.1915–1944)

– Гали Нурулла улы Шәмсетдиновның тууына 110 ел (22.05.1915–1944)

**100** лет со дня рождения Нурми Халяфовича Шарипова (25.02.1925–1944)

– Нурмый Хәләф улы Шәриповның тууына 100 ел (25.02.1925–1944)

**120** лет со дня рождения Бориса Владимировича Шульгина (12.09.1905–1962)

– Борис Владимирович Шульгиннның тууына 120 ел (12.09.1905–1962)

**100** лет со дня рождения Бориса Николаевича (Набиуллы Зайнулловича) Юносова (12.12.1925–1980)

– Нәбиулла Зәйнулла улы (Борис Николаевич) Юнысовның тууына 100 ел (12.12.1925–1980)

**110** лет со дня рождения Карима Мусяковича Ягудина (08.1915–1944)

– Кәрим Муса улы Яһудиннең тууына 110 ел (08.1915–1944)

**110** лет со дня рождения Булата Янбулатовича Янтимирова (1915–1944)

– Булат Янбулат улы Янтимеровның тууына 110 ел (1915–1944)

## Юбилеи кавалеров ордена Славы трёх степеней – наших земляков в 2024 году*

## Якташларыбыз – Дан ордены тулы кавалерларының 2024 елдагы юбилейлары*

**100** лет со дня рождения Михаила Константиновича Алаева (21.11.1925–1946)

– Михаил Константинович Алаевның тууына 100 ел (21.11.1925–1946)

**110** лет со дня рождения Алексея Ивановича Башкирова (24.07.1915–2002)

– Алексей Иванович Башкировның тууына 110 ел (24.07.1915–2002)

**110** лет со дня рождения Александра Алексеевича Заева (15.03.1915–1966)

– Александр Алексеевич Заевның тууына 110 ел (15.03.1915–1966)

**130** лет со дня рождения Миннехана (Минахана) Масгутовича Масгутова (1895–1945)

– Миңнехан Мәсгуть улы Мәсгутовның тууына 130 ел (1895–1945)

**110** лет со дня рождения Бориса Николаевича Плотникова (21.07.1915–1969)

– Борис Николаевич Плотниковның тууына 110 ел (21.07.1915–1969)

**110** лет со дня рождения Николая Ивановича Семёнова (12.07.1915–1998)

Николай Иванович Семёновның тууына 110 ел (12.07.1915–1998)

***Очерки о жизненном пути Героев см.:**
**Геройларның тормыш юллары турындагы очеркларны кара:**
Кавалеры ордена Славы трёх степеней = Дан орденының тулы кавалерлары. – Казань: Книга Памяти, 2005. – 247 с. – На рус. и татар. яз.

# Юбилеи Героев Социалистического Труда – наших земляков в 2024 году*

# Якташларыбыз – Социалистик Хезмәт Геройларының 2024 елдагы юбилейлары*

**100** лет со дня рождения Саита Файзрахмановича Габбазова (13.09.(по другим данным 8.09) 1925–2007)

– Сәит Фәйзрахман улы Габбазовның тууына 100 ел (13.09.(кайбер чыганаклар буенча 8.09) 1925–2007)

**90** лет со дня рождения Надежды Николаевны Галочкиной (04.09.1935–2009)

– Надежда Николаевна Галочкинаның тууына 90 ел (04.09.1935–2009)

**100** лет со дня рождения Асгата Гариповича Гарипова (15.01.1925–2001)

– Әсгать Гариф улы Гариповның тууына 100 ел (15.01.1925–2001)

**90** лет со дня рождения Наиля Мингазовича Гилязова (13.07.1935–2014)

– Наил Минһаҗ улы Гыйләҗевның тууына 90 ел (13.07.1935–2014)

**100** лет со дня рождения Габбаса Киямовича Гиматдинова (08.02.1925–1997)

– Габбас Кыям улы Гыйматдиновның тууына 100 ел (08.02.1925–1997)

**110** лет со дня рождения Ивана Ивановича Журина (28.03.1915–2001)

– Иван Иванович Журинның тууына 110 ел (28.03.1915–2001)

**100** лет со дня рождения Назипа Зиатдиновича Зиатдинова (25.07.1925–2008)

– Нәҗип Зыятдин улы Зыятдиновның тууына 100 ел (25.07.1925–2008)

**80** лет со дня рождения Зуфара Минтимеровича Иманова (01.01.1945–2001)

– Зөфәр Миңтимер улы Имановның тууына 80 ел (01.01.1945–2001)

**80** лет Мударису Абдулловичу Исламгалееву (25.10.1945)

– Мөдәррис Абдулла улы Исламгалиевкә 80 яшь (25.10.1945)

***Очерки о жизненном пути Героев см.:**
**Геройларның тормыш юллары турындагы очеркларны кара:**

Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы – наши земляки = Социалистик Хезмәт геройлары һәм Хезмәт даны орденының тулы кавалерлары – безнең якташларыбыз. – Казань, 2003. – 232 с. – На рус. и татар. яз.

Герои Труда Татарии 1920–1938 гг.: док. очерки. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. – 304 с.
Герои Социалистического Труда (1938–1978 гг.): (док. очерки). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. – 383 с.
Герои Социалистического Труда Татарии: док. очерки. Кн.2. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 352 с.

**100** лет со дня рождения Гусмана Хафизовича Латыпова (13.05.1925–2000)

– Госман Хафиз улы Латыповның тууына 100 ел (13.05.1925 – 2000)

**120** лет со дня рождения Макара Михайловича Лукина (14.05.1905–1961)

– Макар Михайлович Лукинның тууына 120 ел (14.05.1905–1961)

**90** лет Легии Файзрахмановне Мухаметзяновой (25.05.1935)

– Легия Фәйзрахман кызы Мөхәммәтҗановага 90 яшь (25.05.1935)

**100** лет со дня рождения Сарвар Нафиковны Нафиковой (06.09.1925–2012)

– Сәрвәр Нәфыйк кызы Нәфыйкованың тууына 100 ел (06.09.1925–2012)

**100** лет со дня рождения Александра Алексеевича Павлова (15.01.1925–2001)

– Александр Алексеевич Павловның тууына 100 ел (15.01.1925–2001)

**110** лет со дня рождения Газифы Хасановны Хасаншиной (25.01.1915–1986)

– Газифә Хәсән кызы Хәсәншинаның тууына 110 ел (25.01.1915–1986)

# СПРАВОЧНО-БИОГРАФИЧЕСКИЕ И БИБЛИОГРАФИЧЕСКИЕ СВЕДЕНИЯ

# БЕЛЕШМӘ-БИОГРАФИК ҺӘМ БИБЛИОГРАФИК МӘГЪЛҮМАТЛАР

## 10 (24) января / гыйнвар



### Национальная библиотека Республики Татарстан

### Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

**1865**

**160 лет со дня открытия**

**ачылуына 160 ел**

Национальная библиотека Республики Татарстан – одна из старейших общедоступных библиотек. Она была открыта в городе Казани 10 (24) января 1865 года как городская публичная библиотека. Основу библиотеки составила коллекция местного библиофила и краеведа Ивана Алексеевича Второва, которая первоначально насчитывала 903 названия и 1908 томов книг и периодических изданий.

В 1906 году в Казани открывается «филиальное отделение» Публичной библиотеки для мусульманского населения, которое становится одним из крупнейших татарских просветительских центров России того времени.

После революции 1917 года Казанская публичная библиотека переименовывается в Центральную губернскую библиотеку, а в 1923 году – в Центральную городскую. Ранее, в 1920 году, ей присваивается имя В.И.Ленина. «Филиальное отделение» для мусульман в 1919 году реорганизуется в городскую библиотеку № 5, в 1922 году – в Центральную восточную библиотеку им. М.Вахитова, а в 1929 году объединяется с Центральной библиотекой.

В 1934 году Центральная библиотека реорганизуется в областную, а в 1941 году – в республиканскую. В 1965 году утверждается новый Устав библиотеки, согласно которому она становится научной. В 1991 году библиотека получает статус Национальной.

В соответствии с Законом Республики Татарстан «О библиотеках и библиотечном деле» Национальная библиотека является главным государственным книгохранилищем национальной и республиканской, российской и зарубежной печати. Библиотека – крупный информационный и научный, культурный и методический центр.

Национальная библиотека Республики Татарстан – центр пропаганды и распространения культуры татарского народа, единственная библиотека мира, занимающаяся вопросами комплектования, сохранения и распространения татарской книги и литературы о республике. Фонд библиотеки насчитывает 3 млн 553 тысячи 650 документов, в том числе 3 млн 305 тысяч 155 экземпляров на русском языке; 156 тысяч 997 – на татарском, 86 тысяч 645 – на иностранных языках, на языках народов России – 4 тысячи 853 экземпляра.

В 2020 году библиотека переехала в обновлённое здание с двумя читальными залами, шестью книгохранилищами, выставочным пространством, конференц-залом и собственной театральной площадкой. Проект обновления здания разрабатывало архитектурное бюро «ХОРА», которое занималось реконструкцией библиотек г. Москвы.

С переездом в новое здание Национальная библиотека Республики Татарстан трансформировалась в уникальное многофункциональное креативное пространство с новыми смыслами и возможностями. Сегодня это центр притяжения интеллектуальных и креативных сообществ, где не только хранится, но и формируется новое культурное наследие Республики Татарстан. Здесь происходит син-

тез самых разных направлений культуры: изобразительного и перформативного искусств, дизайна, музыки, театра, кино, архитектуры, издательского и выставочного дела и многого другого.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе – Россиядәге иң зур милли китап хәзинәләренең берсе. Ул Казанда 1865 елның 10 (24) гыйнварында Казан шәһәр җәмәгать китапханәсе буларак ачыла. Китапханәнең нигезен библиофил һәм туган якны өйрәнүче Иван Алексеевич Второвның коллекциясе тәшкил итә. Коллекция 903 исемдәге 1908 китаптан һәм көндәлек матбугат басмаларыннан торган.

1906 елда мөселманнар өчен китапханәнең махсус бүлекчәсе – «Көтепханәи исламия» ачылып, ул татар мәгърифәте һәм мәдәнияте үзәгенә әверелә.

Китапханәнең аталышында да үзгәрешләр еш була. 1917 елгы революциядән соң Казан җәмәгать китапханәсе Үзәк губерна китапханәсе, 1923 елда Үзәк шәһәр китапханәсе итеп үзгәртелә. 1920 елда аңа В.И.Ленин исеме бирелә. «Мөселман бүлекчәсе» 1919 елда 5 номерлы шәһәр китапханәсе, 1922 елда – М.Вахитов исемендәге Үзәк Шәрык китапханәсе итеп үзгәртелә, ә 1929 елда Үзәк китапханә белән берләштерелә. Китапханә 1934 елдан – өлкә, 1941 елдан республика китапханәсе статусында эшли. 1965 елда кабул ителгән устав нигезендә, ул Республика фәнни китапханәсе дип исемләнә. 1991 елда Милли китапханә статусына ия була.

Татарстан Республикасының «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» Законы нигезендә Милли китапханә бүген милли һәм республика, Россия һәм чит ил басмаларын үзендә саклаучы, күптармаклы китапханә-мәгълүмат һәм фәнни-тикшеренү эшләре башкаручы дәүләт оешмасы, мәдәни, библиографик һәм методик үзәк.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе – татар мәдәниятен таныту үзәге, татар китабын һәм республикабыз турындагы әдәбиятны туплау, саклау, тарату мәсьәләләре белән максатчан рәвештә шөгыльләнә торган, Россиядәге, якын һәм ерак чит илләрдәге татар укучыларына хезмәт күрсәтүче китапханәләр белән традицион элемтәләре булган бердәнбер зур китапханә. Аның фондларында 3 млн. 553 мең 650 нөсхә һәртөрле басмалар, шул исәптән рус телендәге 3 млн 305 мең 155 нөсхә, татар телендәге 156 мең 997, чит телләрдәге 86 мең 645, Россия халыклары телендә – 4 мең 853 нөсхә китап һәм башка төр мәгълүмат чыганаклары тупланган.

2020 елда китапханә ике уку залы, алты китап саклагычы, күргәзмәләр мәйданы, конференц-залы һәм үзенең театр мәйданчыгы булган яңартылган бинага күченде. Бинаны яңарту проектын «ХОРА» архитектура бюросы эшләде, ул – Мәскәү китапханәләрен реконструкцияләү белән шөгыльләнгән оешма.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, яңа бинага күчү белән, китапханә генә булып калмыйча, яңа мәгънәләрне һәм мөмкинлекләрне үзенә берләштергән уникаль күпфункцияле креатив киңлеккә әверелде. Бүген бу – интеллектуаль һәм иҗади бергәлекләрне җәлеп итү үзәге, Татарстан Республикасы мәдәни мирасының саклагычы гына түгел, яңа мәдәни мирас формалашу урыны да. Биредә мәдәниятнең төрле юнәлешләре бергәлек тудыра: рәсем һәм перформатив сәнгать, дизайн, музыка, театр, кино, архитектура, нәшрият, күргәзмә эше һәм башкалар.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:

**Национальная библиотека Республики Татарстан: история и современность (к 150-летию со дня основания библиотеки):** библиографический указатель = Татарстан Республикасының Милли китапханәсе: тарих һәм хәзерге заман (китапханә нигезләнүгә 150 ел): библиографик күрсәткеч. – Казань: Милли китап, 2015. – 319 с. – Библиогр.: с. 280–288. – Алф. указ. авт.: с. 289–310. – Указ. географ. названий: с. 311–316. – Текст рус., татар.

**Делешова М.Х.** На языке души / Республиканской научной библиотеке им. В.И.Ленина ТАССР – 125. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. – 127 с.

**Национальная библиотека Республики Татарстан: [книга-альбом] = Татарстан Республикасы Милли китапханәсе:** [китап-альбом] = The National Library of the Republik of Tatarstan: [book-album]. – [Казань]: [Татарское книжное издательство], [2015]. – 375, [4] с.: цв. ил.

**Национальная библиотека Республики Татарстан: к 140-летию со дня основания первой публичной библиотеки в городе Казани / Национальная библиотека Республики Татарстан.** – Казань: Милли китап, 2005. – 92 с.

**Казань (журнал).** – 2015. – № 9. – С. 7–99.

**Тимерзянова М., Мансурова А.** Цифровая трансформация Национальной библиотеки Республики Татарстан // Китапханә. – 2022. – № 1 (53). – С. 22–31.

**Тимерзянова М.** Библиотека из будущего: [Национальная библиотека Республики Татарстан в эпоху цифровизации] // Татарстан. – 2022. – № 9. – С. 50–55.

**Тимерзянова М.Ф.** Вдохновлять, заряжать энергией и давать эффективные инструменты! / интервьюер Е.Тихонова // Библиотека. – 2024. – № 3. – С. 7–16.

**Хадиев И.Г.** Национальная библиотека Республики Татарстан: на пути обновления и цифровой трансформации // Китапханә. – 2021. – № 1 (51). – С. 5–18.

**Хадиев И.** Об уникальных коллекциях Национальной библиотеки Республики Татарстан: [рукописное и книжное наследие] // Китапханә. – 2021. – № 2 (52). – С. 57–64.

**Иванычева О.** Национальная библиотека РТ справила новоселье // Казанские ведомости. – 2020. – 3 сент. – С. 3.

**Мирханова А.** Детские залы, креативные индустрии, «Умные полки» и классическая картотека: [о переезде Национальной библиотеки РТ»] // Казань. – 2020. – № 10. – С. 21–24.

**В Казани состоялся Всероссийский библиотечный конгресс // Российская газета.** – 2024. – 22–28 мая. – С.15.

**Галиев М.** Талисман: публицистик язмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 454 б. – Милли китапханә тарихыннан. – Б. 395–415.

**Милли китапханәгә – 150 ел // Казан утлары.** – 2015. – № 11. – Б.190.

**Тимерҗанова М.** Киләчәк китапханәсе // Татарстан. – 2022. – № 9. – Б. 48–53.

**Һадиев И.Г.** Татарстан Республикасы Милли китапханәсе яңарыш һәм цифрлаштыру юлында // Китапханә. – 2021. – № 1. – Б. 19–27.

**Әхмәдуллина Э.** Гыйлем сарае // Шәһри Казан. – 2000. – 28 гыйнв.

**Локманова Л.** Китап укыр өчен генә килмиләр... // Шәһри Казан. – 2020. – 7 авг. – Б. 5.

**Галиева Р.** Дөнья дәрәҗәсендәге мәдәният // Шәһри Казан. – 2020. – 1 сент. – Б. 5.

**Гыймазова Л.** Саргаймасын битләре // Ватаным Татарстан. – 2021. – 28 май. – Б. 16.

**Карпова Д.** Милли китапханәгә сәяхәт: яшьләр китап укы(мы)й // Ватаным Татарстан. – 2024. – 9 июль. – Б. 4.

## 15 января / гыйнвар



### Махмуд Максуд
### Мәхмүд Максуд

**1900–1962**

**125 лет со дня рождения**
**тууына 125 ел**

Писатель и переводчик Махмуд Максуд (Махмуд Гисамутдинович Махмудов) родился 15 января 1900 года в деревне Верхние Кибя-Кози Лаишевского уезда Казанской губернии (ныне Тюлячинский район Республики Татарстан) в семье сельского муллы. В возрасте пяти-шести лет он научился распознавать буквы у родителей и пристрастился к чтению книг.

Первоначальное образование получил в медресе деревни Кшкар, потом продолжил учёбу в двухклассной русско-татарской школе Арска, затем в 1916–1918 годах учился в Высшем начальном училище города Малмыжа.

Ещё в школьные годы М.Максуд познакомился с произведениями татарских и русских писателей, углублённо изучал русскую литературу, начал писать свои первые ученические стихи и рассказы. Всё это впоследствии положительно сказалось на его литературно-творческой деятельности. В 1918 году опубликовал первый очерк «Бәйрәм җитә» («Приближается праздник») в газете «Чулпан».

В годы гражданской войны М.Максуд с оружием в руках защищает Советскую власть.

В январе 1921 года М.Максуд был направлен на работу в редакцию газеты «Яшь эшче» (1921–1926), издаваемой на татарском языке в Москве. В 1926–1928 годах работал главным редактором издательства «Нәшрият», в 1928–1931 годах руководил секцией татарской литературы «Центриздата», в 1932–1933 годах секцией национальных литератур «Профиздата»; в 1933–1934 годах он – литературный сотрудник в газете «Коммунист».

В это время он, не отрываясь от работы, закончил отделение историко-естественных наук Коммунистического университета трудящихся Востока, в 1934 году литературное отделение этнологического факультета Московского государственного университета.

В годы Великой Отечественной войны М.Максуд находился в действующей армии, служил политруком, батальонным комиссаром, агитатором политотдела, заместителем редактора фронтовой газеты «Совет сугышчысы» («Советский воин»).

М.Максуд – писатель разностороннего дарования. Он поэт и очеркист, автор сборников рассказов, книги воспоминаний о М.Джалиле, литературно-критических статей о творчестве татарских писателей.

М.Максуд – один из тех писателей, которые на протяжении всей жизни последовательно и эффективно работали в области перевода. Огромна его роль как переводчика. Он перевёл на татарский язык произведения русских и зарубежных классиков: «Дубровский» (1934) и «Скупой рыцарь» (1948) А.С.Пушкина, «Кола Брюньон» (1937) Р.Роллана, поэму «Германия» (1939) Г.Гейне, «Песни» (1940) Беранже, «Стихи и поэмы» (1947) Абая, поэму «Лейли и Маджнун» (1950) Низами, «Мать (1951) М.Горького,

«Война и мир» (т.1–4, 1954–1957) и «Анна Каренина» (1960) Л.Н.Толстого, «Рудин» (1959) И.С.Тургенева, сборник «Поэты Прибалтики» и др.

Махмуд Максуд умер 10 ноября 1962 года в Москве, похоронен в Даниловском мусульманском кладбище города.

Язучы һәм тәрҗемәче Мәхмүд Максуд (Мәхмүд Гыйсаметдин улы Максудов) 1900 елның 15 гыйнварында Казан губернасы Лаеш өязенең (хәзер Татарстан Республикасының Теләче районы) Югары Кибәхуҗа авылында мулла гаиләсендә туа. Биш-алты яшендә әтиәнисеннән хәреф танырга өйрәнә һәм китап укырга һәвәс булып үсә. Башлангыч белемне Кышкар мәдрәсәсендә үзләштерә, аннары Арчадагы ике класслы рус-татар мәктәбендә һәм 1916–1918 елларда Малмыж шәһәрендәге «Югары башлангыч училище» дип йөртелгән уку йортында белем ала.

Мәктәп елларында ук М.Максуд татар һәм рус язучыларының әсәрләре белән таныша, рус телен, әдәбиятын тирәнтен өйрәнә, үзе дә беренче өйрәнчек шигырьләрен, хикәяләрен яза башлый. Боларның барысы да соңрак аның әдәби-иҗади эшчәнлегенә уңай йогынты ясый. 1918 елда «Чулпан» газетасында аның «Бәйрәм җитә» исемле беренче очеркы басылып чыга.

Гражданнар сугышы елларында М.Максуд, кулына корал тотып, Совет властен яклый.

1921 елның гыйнварында М.Максуд Мәскәүдә татар телендә нәшер ителә торган «Яшь эшче» (1921–1926) газетасы редакциясенә эшкә җибәрелә. 1926–1928 елларда «Нәшрият» нәшриятында баш редактор була, «Центриздат»та татар әдәбияты секциясен, «Профиздат»та милли әдәбиятлар секторын җитәкли; 1933–1934 елларда «Коммунист» газетасында әдәби хезмәткәр вазифасын башкара.

Шул ук чорда әдип, төп хезмәтеннән аерылмыйча укып, башта Көнчыгыш хезмәт ияләре коммунистик университетының тарих-табигать фәннәре бүлеген, 1934 елда Мәскәү дәүләт университетының этнология факультетында әдәбият бүлеген тәмамлый.

Бөек Ватан сугышының беренче көненнән алып М.Максуд фронтта – политрук, батальон комиссары, политбүлек агитаторы, «Совет сугышчысы» исемле фронт газетасының редактор урынбасары булып хезмәт итә.

М.Максуд – күпкырлы талант иясе. Ул шагыйрь һәм очеркчы, хикәяләр җыентыклары, М.Җәлил турында истәлекләр китабы, татар язучылары иҗаты турында әдәби-тәнкыйть мәкаләләре авторы.

М.Максуд – бөтен гомере буена тәрҗемә өлкәсендә эзлекле рәвештә һәм нәтиҗәле эшләп килгән язучыларның берсе. Ул татар теленә рус һәм чит ил классик язучыларының бик күп әсәрләрен: А.С.Пушкинның «Дубровский» (1934) һәм «Саран рыцарь» («Скупой рыцарь», 1948), Р.Ролланның «Кола Брюньон» (1937), Г.Гейненың «Германия» (1939) поэмасын, Беранженың «Җырлар» ын («Песни», 1940), Абайның «Шигырьләр һәм поэмалар» («Стихи и поэмы», 1947), Низаминың «Ләйлә белән Мәҗнүн» (1950) поэмасын, М.Горькийның «Ана» («Мать», 1951), Л.Н.Толстойның «Сугыш һәм тынычлык» («Война и мир», 1–4 т., 1954–1957) һәм «Анна Каренина» (1960), И.С.Тургеневның «Рудин» (1959) әсәрләрен, «Балтик буе шагыйрьләре» («Поэты Прибалтики») җыентыгын һ.б. тәрҗемә итә.

Мәхмүд Максуд 1962 елның 10 ноябрендә Мәскәүдә вафат була, шәһәрнең Данилов мөселман зиратында җирләнә.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:

**Максуд М.** Әсәрләр: бертомлык (1919–1959) / Х. Хәйри кереш сүзе б-н. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 663 б.: портр.

**Максуд М.** Сагынган минутларда: Муса Җәлил турында истәлекләр һәм уйланулар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – 190 б.

**Максуд М.** Яңа тормыш язында: хикәяләр, шигырьләр, мәкаләләр һәм очерклар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 255 б.: портр. – Библиогр. белешмә: б. 238–252.

**Максуд М.** Яз җыры: хикәя, нәсер, истәлек һәм очерклар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 129 б.: рәс. – Биографик белешмә: б. 127–128.

**Максуд М.** Патриот Тукай // Безнең мирас. – 2024. – май (№ 5). – Б. 70.

**Гиниятуллина А.** Писатели Советского Татарстана: биобиблиогр. спр. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 511 с. – Махмуд Максуд. – С. 283–285.

**Сафаров М.** Махмуд Максуд. На заре новой жизни // Идель. – 2020. – № 8. – С. 44–47.

**Закиров А.** Семантико-стилевые особенности перевода на татарский язык романа Л.Н.Толстого «Анна Каренина»: / [перевод М.Максуда] // Филология и культура. – 2017. – № 3 (49). – С. 146–153.

**Саяпова А.** Проблема сохранения национальной окраски в переводах художественной литературы (на примере переводов М.Лозинским и М.Максудом романа Р.Роллана «Кола Брюньон») // Филология и культура. – 2017. – № 3 (49). – С. 208–213.

**Саяпова А.** Перевод как связь между культурами: роман Л.Н.Толстого «Анна Каренина» в интерпретации татарского переводчика: [перевод М. Максуда] // Филология и культура. – Казань. – 2023. – № 4 (74). – С. 175–180.

**Әдипләребез: биобиблиогр. белешмәлек. 2 томда.** Т. 2 / [төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 735 б. – Мәхмүд Максуд. – Б. 55–59.

**Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б.** Совет Татарстаны язучылары: биобиблиогр. белешмә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 639 б. – Мәхмүд Максуд. – Б. 30–32.

**Шамов А.** Зур тормыш // Казан утлары. – 1970. – № 1. – Б. 139–143.

**Мәхмүд Максудның тууына 100 ел** // Казан утлары. – 2000. – № 1. – Б. 188.

# 19 января / гыйнвар



## Азат Аббасов

**1925–2006**

**100 лет**
**со дня рождения**
**тууына 100 ел**

Один из замечательных представителей татарского музыкального искусства – Азат Зиннатович Аббасов – родился 19 января 1925 года в Елабуге. После окончания семи классов школы поступет в Казанский авиационный техникум и, окончив его в 1943 году, начинает работать конструктором на Казанском вертолётном заводе.

Семья Аббасовых была по-своему музыкальной: в ней любили песню, музыку, хорошо знали татарский песенный фольклор. Его отец, обладающий красивым и могучим басом, пел народные татарские песни. Друг семьи, композитор С.Сайдашев, услышав

пение Азата, посоветовал ему попробовать профессионально учиться пению.

В 1944 году А.Аббасов поступает в Татарскую оперную студию при Московской государственной консерватории, а закончив её в 1950 году, возвращается в Казань. Дебютирует на сцене Татарского театра оперы и балета в партии Трике («Евгений Онегин» П.Чайковского). С тех пор его жизнь неразрывно связана с этим театром, в 1950–1990 годах он – один из ведущих солистов. А.Аббасов проявляет себя как разносторонний исполнитель партий героико-эпического, трагедийного, романтического плана в операх, опереттах, музыкальных комедиях западно-европейских и русских классиков, современных композиторов.

Артистом исполнено более 100 партий: Фауст («Фауст» Ш.Гуно), Ричард («Бал маскарад» Дж. Верди), Рудольф, Каварадосси, Пинкертон («Богема», «Тоска», «Чио-Чио-сан» Дж. Пуччини), Самозванец («Борис Годунов» М.Мусоргского). Андрей («Семья Тараса» Д.Кабалевского), Алексей («Оптимистическая трагедия» А.Холминова), Сергей («Катерина Измайлова» Д.Шостаковича) и др. Исполняет главные роли в опереттах и мюзиклах «Летучая мышь» и «Цыгынский барон» И.Штрауса, «Моя прекрасная леди» Ф.Лоу, «Севастопольский вальс» К.Листова, «Ромео – мой сосед» Р.Гаджиева.

А.Аббасов внёс большой вклад в национальное музыкально-сценическое искусство как исполнитель главных партий в произведениях татарских композиторов: Джик, Джалиль, Туляк («Алтынчеч», «Джалиль», «Тюляк» Н.Жиганова), Самат («Самат» Х.Валиуллина), Галимджан, Карим бай («Башмачки» Дж.Файзи). В каждом спектакле артист находит своеобразные неповторимые штрихи, характеризующие его героев.

В 1955–1962 годах А.Аббасов с успехом выступает в роли Булата в музыкальной драме К.Тинчурина и С.Сайдашева «Голубая шаль» на сцене Татарского академического театра им. Г.Камала.

Большое место в творчестве А.Аббасова занимает концертная деятельность. Он является лучшим исполнителем произведений С. Сайдашева, М.Музаффарова, Дж.Файзи, А.Ключарёва, Р.Яхина и др. татарских композиторов.

А.Аббасов – обладатель голоса красивого тембра, ярких внешних артистических данных. Органично сочетая вокальное и актёрское мастерство, достиг высокого уровня исполнительской культуры.

Высоко оценены заслуги А.З.Аббасова в развитии вокального искусства: ему были присвоены почётные звания заслуженного артиста Татарской АССР (1956), заслуженного артиста РСФСР (1957), народного артиста РСФСР (1966), народного артиста СССР (1977); он – лауреат Государственной премии Татарстана им. Г.Тукая (1971), Почётный гражданин Казани (2005).

Азат Зиннатович Аббасов умер 11 октября 2006 года в Казани.

Татар музыка сәнгатенең күренекле вәкилләреннән берсе – Азат Зиннәт улы Аббасов – 1925 елның 19 гыйнварында Алабуга шәһәрендә туа. Мәктәптә җиде сыйныфны тәмамлаганнан соң, Казан авиация техникумына укырга керә һәм аны 1943 елда тәмамлап, Казан вертолёт заводында конструктор булып эшли башлый.

Әмма табигатьтән килә торган сәләт, гаиләтрадицияләре үзенекен итә. Матур, көчле бас тавыш белән татар халык көйләрен җырларга яраткан әтисе Зиннәттән Азат

җырга мәхәббәт кабул иткән. Аббасовлар гаиләсенең дусты композитор С.Сәйдәшев, Азатның җырлавын ишеткәч, аңа җырчы булырга, укырга киңәш итә.

1944 елда А.Аббасов Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясенә укырга керә һәм югары вокал мәктәбе үтә. 1950 елда укуын тәмамлагач, Казанга кайта. Беренче тапкыр Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә Трике («Евгений Онегин», П.Чайковский) партиясен башкара. Шуннан бирле аның тормышы әлеге театр белән аерылгысыз, 1950–1990 елларда ул театрның әйдәп баручы солистларының берсе була. А.Аббасов Көнбатыш Европа, рус һәм хәзерге заман композиторларының операларында, оперетталарында, музыкаль комедияләрендә үзен героик-эпик, фаҗигале рухтагы партияләрне башкарырга сәләтле җырчы итеп таныта.

Театрда А.Аббасов йөздән артык спектакльдә: Фауст («Фауст», Ш.Гуно), Ричард («Бал маскарад», Дж.Верди), Рудольф, Каварадосси, Пинкертон («Богема», «Тоска», «Чио-Чио-сан», Дж.Пуччини), Самозванец («Борис Годунов», М.Мусоргский), Андрей («Тарас гаиләсе», Д.Кабалевский), Алексей («Оптимистическая трагедия», А.Холминов), Сергей («Катерина Измайлова», Д.Шостакович) һ.б. образлар тудыра. И.Штрауснның «Ярканат» һәм «Чегән бароны», Ф.Лоуның «Гүзәл ханым минем», К.Листовның «Севастополь вальсы», Р.Гаджиевның «Ромео – минем күршем» оперетта һәм мюзиклларында баш рольләрне башкара.

Татар композиторларыннан: Н.Җиһановның «Алтынчәч», «Җәлил», «Түләк һәм Сусылу» (Җик, Муса Җәлил, Түләк), Х.Вәлиуллинның «Самат» (Самат), Җ.Фәйзинең «Башмагым» (Галимҗан, Кәрим бай) әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә төп партияләрне башкарып, милли музыка һәм сәхнә сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертә. Актёр һәрбер ролен башкарганда яңа алымнар файдалана, кабатланмас төсмерләр кертә.

1955–1962 елларда А.Аббасов Г.Камал исемендәге Татар академия театры сәхнәсендә К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» (С.Сәйдәшев музыкасы) спектаклендәге Булат ролен зур уңыш белән башкара.

А.Аббасов иҗатында концерт эшчәнлеге дә зур урын алып тора. Ул – С.Сәйдәшев, М.Мозаффаров, Җ.Фәйзи, А.Ключарёв, Р.Яхин һ.б. татар композиторларының әсәрләрен иң оста башкаручы да.

Азат Аббасов – кабатланмас матур тембрлы тавышка ия җырчы; вокаль һәм актёрлык осталыкларын органик куша белүе белән башкару культурасының югары баскычына күтәрелә.

А.З.Аббасовның вокаль сәнгатьне үстерүдәге казанышлары югары бәяләнә: аңа Татарстан АССРның атказанган артисты (1956), РСФСРның атказанган һәм халык артисты (1957, 1966), СССРның халык артисты (1977) дигән мактаулы исемнәр бирелә; ул – Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1971), Казан шәһәренең Мактаулы гражданины (2005).

Азат Зиннәт улы Аббасов 2006 елның 11 остябрендә Казанда вафат була.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:

**Махмутова А.** Любовь всей жизни – опера // Сәхнә. – 2015. – № 2. – Б. 32–33.

**Малахальцев А.** Его святая к опере любовь // Республика Татарстан. – 2005. – 15 нояб.

**Аббасов А.** «Язмыш дигәне шулдыр…» / әңгәмәне алып баручы З.Кыдашева // Татарстан яшьләре. – 2005. – 10 нояб.

**Аббасов А.** Читлектәге арслан / әңгәмәне алып баручы А.Юнысова // Ватаным Татарстан. – 2005. – 22 гыйн.

**Салих абый фатихасы белән** / әңгәмәне алып баручы А.Рахман // Татарстан. – 1995. – № 5–6. – Б. 77–81.

**Бикчурина Ф.** Бәхет китерүче осталык // Казан утлары. – 1985. – № 1. – Б. 188–189.

**Әгъләм М.** Операбызның алтын баганасы // Шәһри Казан. – 1995. – 27 окт.

**Гыйләҗев Х.** Татарның опера патшасы // Шәһри Казан. – 2003. – 11 июль.

**Юнысова А.** Ярый әле ул бар // Ватаным Татарстан. – 2005. – 16 нояб.

**Хәбибуллина Л.** Иң биек үрне яулаган җырчы // Шәһри Казан. – 2005. – 18 нояб.

**Галиуллина М.** Җыр аны үлемсез итте… // Мәдәни җомга. – 2015. – 23 гыйнвар. – Б.15.

## 11 февраля / февраль



### Василий Иванович Качалов

**1875–1948**

**150 лет со дня рождения**
**тууына 150 ел**

Василий Иванович Качалов (настоящая фамилия Шверубович) родился 11 февраля 1875 года в городе Вильно (сейчас носит название Вильнюс) в семье священника. Он получил хорошее образование, учился в гимназии.

Учился на юридическом факультете Санкт-Петербургского университета, принимал участие в спектаклях студенческого драматического кружка под руководством В.Н.Давыдова, одновременно, в 1896–1897 годах, работал приходящим (нештатным) актёром в Суворинском театре.

В конце августа 1897 года В.Качалов приехал в Казань, не закончив учёбу в университете. Здесь он предполагал продолжить учёбу на юридическом факультете и выступать на казанской сцене.

В конце XIX–начале XX века Казань имела репутацию театрального города, в городе была многочисленная театральная публика. В 1897 году В.Качалов был принят в Казанско-Саратовское товарищество М.М.Бородая и 9 сентября 1897 года впервые вышел на казанскую сцену в небольшой роли барона Раццеля в комедии К.А.Тарновского «Когда б он знал».

«Один из талантливейших людей театрального мира», – так называл В.Качалов возглавлявшего в то время театральное дело Казани М.М.Бородая.

Три сезона выступал В.Качалов в Казани, но они имели большое значение в судьбе актёра. Вначале на сцене казанского театра он выступал в небольших ролях, взяв по настоянию антрепренёра псевдоним «Качалов». Среди крупных и интересных актёров быстро прошёл школу профессионального мастерства, здесь впервые проявилось артистическое дарование. Его изумительный голос, блестящий актёрский талант был вскоре замечен и в конце сезона он был занят в серьёзных ролях. На протяжении трёх сезонов в Казани В.Качалов сыграл более 150 ролей различного плана. Наивысшую оценку казанской прессы получило исполнение Качаловым ролей Бориса Годунова («Смерть Иоанна Грозного» А.К.Толстого), Кассия («Юлий Цезарь» У.Шекспира), Несчастливцева («Лес» А.Н.Островского). Ему помогали природный ум, артистизм, профессиональное упорство и

овладение ролью. Именно в казанской сцене сформировались важнейшие стороны его дарования.

В годы пребывания в Казани Качалов принимал активное участие в общественных мероприятиях: благотворительных концертах, студенческих вечерах; его исполнение стихотворений А.С.Пушкина, М.Ю.Лермонтова, монологов из пьес А.С.Грибоедова, У.Шекспира пользовалось большой популярностью.

В январе 1900 года В.Качалов был приглашён К.С.Станиславским и В.И.Немировичем-Данченко в Московский Художественный театр, в период работы в котором его творчество получило всемирное признание.

Перед отъездом в Москву, в середине февраля В.Качалов перед казанской публикой с прощальным концертом выступил в Дворянском собрании. Зрители тепло проводили В.Качалова, а студенты преподнесли ему лавровый венок с дружеской надписью на ленте.

За свою творческую деятельность В.И.Качалов был удостоен звания народного артиста СССР и лауреата Государственной премии СССР.

Василий Иванович Качалов умер 30 сентября 1948 года.

Память о любимом артисте хранят жители Казани. В 1948 году имя В.И.Качалова присвоено Казанскому Большому драматическому театру. Именем Качалова названа одна из улиц Казани. На фасаде дома № 3 по улице Лобачевского (бывшие «Номера Михайлова»), в котором жил в своё время актёр, установлена мемориальная доска. В 2005 году во внутреннем дворике (атриуме) Казанского Большого драматического театра ему был открыт памятник (скульптор А.М.Миннуллина, архитектор Г.А.Бакулин).

Василий Иванович Качалов (чын фамилиясе Шверубович) 1875 елның 11 февралендә Вильно шәһәрендә (хәзерге исеме Вильнюс) рухани гаиләсендә туа. Ул яхшы белем ала, гимназиядә укый.

Санкт-Петербург университетының юридик факультетында укый, В.Н.Давыдов җитәкчелегендәге студентлар драма түгәрәге спектакльләрендә катнаша, бер үк вакытта, 1896–1897 елларда Суворин театрында штаттан тыш актёр булып эшли.

1897 елның август ахырында Качалов, университетта укуын тәмамламыйча, Казанга килә. Биредә ул юридик факультетта укуын дәвам итәргә һәм Казан сәхнәсендә чыгыш ясарга ниятли.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Казан театр шәһәре буларак танылган, шәһәрдә күпсанлы театр тамашачысы булган. В.Качалов 1897 елда М.М.Бородайның Казан-Саратов ширкәтенә кабул ителә һәм шул ук елның 9 сентябрендә К.А.Тарновскийның «Ул белгән булса» комедиясендәге зур булмаган барон Раццель роле белән беренче тапкыр Казан сәхнәсенә чыга.

В.Качалов бу елларда Казан театрын җитәкләгән М.М.Бородайны «Театр дөньясының иң талантлы кешеләреннән берсе» дип атый.

В.Качалов Казанда өч сезонда чыгыш ясый, әмма алар актёр язмышында зур роль уйный. Башта Казан театры сәхнәсендә ул кечкенә рольләр башкара, антрепренёр кушуы буенча «Качалов» псевдонимын ала. Монда ул олы һәм танылган актёрлар арасында профессиональ иҗат юлын башлый, тәҗрибә мәктәбе үтә, талантының иң яхшы яклары шушы театрда ачыла. Аның гаҗәеп тавышы, искиткеч артистлык осталыгы бик тиздән тамашачыларны җәлеп итә һәм сезон ахырында ул җитди рольләр дә башкара. Өч сезон дәвамында В.Качалов Казанда 150 дән артык

төрле рольләр башкара. Борис Годунов («Иоанн Грозныйның үлеме», А.К.Толстой), Кассий («Юлий Цезарь», У.Шекспир), Несчастливцев («Урман», А.Н.Островский) рольләре өчен Казан вакытлы матбугатының иң югары бәясенә лаек була. Аңа табигый акыл, артистлык, профессиональ тырышлыгы рольгә кереп китәргә ярдәм итә. Нәкъ менә Казан сәхнәсендә аның талантының мөһим яклары формалаша.

Казанда яшәгән елларында В.Качалов җәмәгать чараларында – хәйрия концертларында, студентлар кичәләрендә актив катнаша: А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов шигырьләрен сәнгатьле укуы, А.С.Грибоедов, У.Шекспир пьесаларыннан монологларны оста башкаруы белән дан казана.

1900 елның гыйнварында В.Качалов К.С.Станиславский и В.И.Немирович-Данченко тарафыннан Мәскәү Сәнгать театрына алына, монда эшләгән елларында аның иҗаты бөтен дөньяга танылa.

Мәскәүгә китәр алдыннан, февраль урталарында, Качалов Казан тамашачысы каршында саубуллашу концерты белән чыгыш ясый. Казанлылар артистны бик җылы озаталар, ә студентлар дусларча сүзләр язылган тасмалы лавр веногы – җиңү таҗы бүләк итәләр.

Үзенең иҗади эшчәнлеге өчен В.И.Качалов СССРның халык артисты исемен ала һәм СССРның Дәүләт премиясенә лаек була.

Василий Иванович Качалов 1948 елның 30 сентябрендә вафат була.

Яраткан артистларын казанлылар онытмыйлар. 1948 елда Казан Зур драма театрына В.И.Качалов исеме бирелә. Казан урамнарының берсе Качалов исемен йөртә. Элек артист яшәгән Лобачевский урамындагы 3 нче номерлы йортка (элекке «Михайлов номерлары») мемориаль такта, 2005 елда Казан Зур драма театрының ишегалдында (атриумда) аңа һәйкәл куела (скульпторы А.М.Миннуллина, архитекторы Г.А.Бакулин).

## Советуем прочитать: Укырга тәкъдим итәбез:

**Василий Иванович Качалов** // Самые знаменитые артисты России. – М.: Вече, 2000. – С. 154–160.

**Благов Ю.А.** Качалов и качаловцы. Часть 1. – Казань: Реноме, 2008. – 171 с. – Три казанских сезона. – С. 5–29.

**Крути И.А.** Русский театр в Казани: материалы к истории провинциального драматического театра. – М.: Искусство, 1958. – 396 с. – Библиогр. в подстроч. примеч. – Прим.: с. 380–395.

**Харис Р.** Замана һәм каләм: әдәбият, сәнгать, публицистика = Время и перо: литература, искусство, публицистика. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 366 б.: портр. – Слово о Качалове (к 100-летию актёра). – С. 101–102. – Кит. татар., рус. тел.

**Любимова О.** Фамильная ценность // Аргументы и факты + прилож. «Регион». – 2015. – 25 февраля–3 марта. – С. 15.

**Шверубович М.Ю., Любимов Б.** Качалов взял свой псевдоним из газетного некролога: [беседа с внучкой В.Качалова и её мужем] / беседовала О. Иванычева // Казанские ведомости. – 2014. – 4 дек. – С. 4.

**Стрельцова О.** Качаловские сезоны // Респ. Татарстан. – 2020. – 20 февр. – С. 15.

**Благов Ю.** Постоялец из номеров Михайлова // Респ. Татарстан. – 2002. – 5 сент. – С. 11.

**Благов Ю. Т**ри Казанских сезона // Казань. – 2005. – № 1. – С. 91–96.

**Благов Ю.** «Васюку Качалову на добрую па-

мять»: [о письмах, хранящихся в библиотеке Казанского университета] // Респ. Татарстан. – 2005. – 19 февр.

**Амиров К.Ф.** Казанских улиц имена / К.Ф.Амиров, Р.Х.Ахметзянова, Р.Г.Вениаминов. – Казань: Центр инновационных технологий, 2008. – 589 с. – Качалов. – С. 231–233.

**Малахальцев А.** Василий Качалов в бронзе и благодарной памяти // Респ. Татарстан. – 2005. – 20 окт.

**Иванычева О.** Василий Качалов: возвращение в Казань: [в фойе-атриуме Казанского академического русского Большого театра им. Качалова открылась выставка] // Казанские ведомости. – 2020. – 18 сент. – С. 8.

## 14 февраля / февраль



### Каюм Насыри
### Каюм Насыйри

**1825–1902**

**200 лет со дня рождения**
**тууына 200 ел**

Учёный-энциклопедист, просветитель, педагог, писатель К.Насыри всю свою жизнь отдал просвещению родного народа, служению науке, истории, литературе.

Каюм Насыри (Габделкаюм Габденнасырович Насыров) родился 14 февраля 1825 года в деревне Верхние Ширданы Свияжского уезда Казанской губернии (ныне Зеленодольский район Республики Татарстан) в семье муллы. Отец и дед его были образованными людьми. Первоначальное образование он получает в медресе своего отца.

В 1841–1855 годах Каюм Насыри учится в медресе при Пятой соборной мечети Казани. Там он получил богословское образование, освоил арабский, персидский языки, самостоятельно изучил русский язык, затем был вольнослушателем Казанского университета.

В 1855–1871 годах К.Насыри преподаёт татарский язык в Казанском духовном училище и Казанской духовной семинарии.

Работа в русском учебном заведении позволила ему ещё лучше изучить русский язык.

В 1871 году он организует светскую начальную школу для детей-татар по изучению русского языка, в которой работает восемь лет.

Творческая и литературная деятельность Каюма Насыри началась в конце 1850-х годов. Он внёс заметный вклад в развитие различных отраслей гуманитарных наук, заложил основы современного татарского литературного языка, его научной терминологии. Первым печатным его трудом был учебник «Краткая татарская грамматика», вышедший в свет в 1860 году.

С 1879 года К.Насыри полностью посвящает себя литературной и научной деятельности: создаёт, наряду с многочисленными художественными произведениями, фундаментальные труды по филологии, педагогике, математике, географии, астрономии, географии, земледелию, народной медицине, истории, этнографии, педагогике, устному народному творчеству, литературоведению, переводит с разных языков, в том числе труды по различным отраслям науки.

В течение 24 лет (в 1871–1897 годах, с перерывом в 1886, 1887 и 1895) К.Насыри издаёт ежегодный календарь на татарском языке («Казан календаре»), в котором, помимо собственно календарных сведений, помещалось множество научного и литературного материала.

Он был истинным учёным, богато одарённым, всесторонне развитым человеком своего времени.

В 1885 году К.Насыри избирают действительным членом Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. Это было официальным признанием его научных заслуг.

В течение своей более чем полувековой научной, литературной и педагогической деятельности К.Насыри в общей сложности написал более сорока книг, оставил большое рукописное наследие. Своей просветительской миссией он сыграл трудно переоценимую роль в приобщении большей части татарского общества к современным знаниям и наукам нового времени.

Ушёл из жизни Каюм Насыри 2 сентября 1902 года в Казани, похоронен на кладбище Ново-Татарской слободы.

Именем Каюма Насыри названа одна из улиц в Старо-Татарской слободе города Казани. 1 марта 1997 года в деревне Б.Ачасыры Зеленодольского района Республики Татарстан открылся архитектурно-этнографический музей его имени. В Казани музей Каюма Насыри работает с 2002 года.

Энциклопедист-галим, мәгърифәтче, педагог, язучы К.Насыйри бөтен гомерен туган халкына, мәгърифәткә, фәнгә, тарихка, әдәбиятка хезмәт итүгә багышлаган.

Каюм Насыйри (Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров) 1825 елның 14 февралендә Казан губернасының Зөя өязе (хәзерге Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы) Югары Ширдан авылында мулла гаиләсендә туа. Аның әтисе һәм бабасы – заманының шактый укымышлы кешеләре булалар. Башлангыч белемне атасы мәдрәсәсендә ала.

1941–1855 елларда Каюм Насыйри Казанның бишенче мәхәллә мәдрәсәсендә укый. Анда ул дини белем ала, гарәп, фарсы телләрен үзләштерә, үзлегеннән рус телен өйрәнә, соңыннан Казан университетына иректе тыңлаучы булып керә.

1855–1871 елларда Каюм Насыйри Казан рухани училищесында һәм Казан рухани семинариясендә татар теле укыта. Рус уку йортында эшләү аңа рус телен яхшырак өйрәнергә мөмкинлек бирә.

1871 елда ул Казанда татар балаларына рус телен өйрәтү өчен башлангыч дөньяви белем бирү мәктәбен оештыра һәм анда сигез ел эшли.

К.Насыйриның иҗади һәм әдәби эшчәнлеге 1850 нче елларның ахырында башлана. Ул гуманитар фәннәрнең төрле тармакларын үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә, хәзерге татар әдәби теленә, аның фәнни терминологиясенә нигез сала. Аның беренче басма хезмәте 1860 елда дөнья күргән «Краткая татарская грамматика» дәреслеге була.

1879 елдан К. Насыйри үзен тулысынча язучылык эшенә һәм фәнгә багышлый: күпсанлы әдәби әсәрләр иҗат итү белән беррәттән, тел белеме, педагогика, математика, география, астрономия, география, игенчелек, халык медицинасы, тарих, этнография, халык авыз иҗаты, әдәбият белеме, төрле телләрдән, шул исәптән фәннең төрле тармаклары буенча, тәрҗемә итеп, фундаменталь хезмәтләр язып калдыра.

24 ел буена (1871–1897 елларда дөнья күрә; 1886, 1887 һәм 1895 елларда гына чыкмый кала) татар телендә еллык календарьлар («Казан календаре») чыгарып килә. Календарьларында башка бик күп төрле язмалар белән бергә, даими рәвештә фәнни һәм әдәби язмалар да бастырып бара. Ул чын галим, үз заманының сәләтле, һәрьяклап киң белемле кешесе була.

1885 елда К.Насыйри Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы итеп сайлана. Әлеге җәмгытькә сайлану – аның фәнни казанышларын рәсми рәвештә тану була.

Ярты гасырдан артык фәнни, әдәби һәм педагогик эшчәнлеге дәвамында К. Насыйри, гомумән алганда, кырыктан артык китап язган, бай кулъязма мирас калдырган. Үзенең мәгърифәтчелек эшчәнлеге белән ул татар җәмгыятенең күп өлешен заманча белемгә һәм фәнгә тарта һәм бу күренеш үз чоры өчен зур роль уйный.

Каюм Насыйри 1902 елның 2 сентябрендә Казанда вафат була, Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнә.

Казан шәһәре Иске-Татар бистәсенең бер урамы Каюм Насыйри исемен йөртә. 1997 елның 1 мартында Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Олы Ачасыр авылында аның исемендәге архитектура-этнография музее ачыла. Казанда Каюм Насыйри музее 2002 елдан эшли.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:

**Насыри К.** Избранные произведения / сост.: С.Х.Алишев, М.В.Гайнутдинов, Х.Ш.Махмутов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. – 254 с.: ил.

**Насыри К.** Сказания о мудром Абу Али Сине, его брате Абу Али Харисе и невероятных приключениях, которые были с ними / пересказала с татар. для детей С. Гильмутдинова, худож. Ш. Шайдуллин. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1981. – 128 с.

**Насыри К.** Наставления повару = Иршад элэтбиха / Институт экономики, управления и права. – Казань: Познание, 2015. – 43 с. – (Сокровищница Татарстана). – Текст парал.: рус., тат. – Книга перевёртыш.

**Насыйри К.** Сайланма әсәрләр: 4 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003–2006.

Т. 1: / төз., гарәп графикасында сакланган текстларны гамәлдәге язуга күчерүче М.Гайнетдин. – 2003. – 366 б.

Т. 2: / төз., гарәп графикасында сакланган текстларны гамәлдәге язуга күчерүче М.Гайнетдин. – 2004. – 398 б.

Т. 3: / төз., гарәп графикасында сакланган текстларны гамәлдәге язуга күчерүче, кереш сүз язучы Х.Мәхмүтов. – 2005. – 382 б.

Т. 4: / гарәп графикасында сакланган текстларны гамәлдәге язуга күчерүче М.Гайнетдин; кереш сүз язучы Р. Кадыйров. – 2006. – 398 б.

**Насыйри К.** Сайланма әсәрләр: ике томда / Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты. – Казан: Татар кит. нәшр., 1974–1975.

Т. 1. – 1974. – 340 б.: портр.

Т. 2. – 1975. – 320 б. – Библиогр.: б. 289–313.

**Насыйри К.** Әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1971. – 143 б. – (Мәктәп китапханәсе).

**Насыйри К.** Китаб-әт-тәрбия = Книга о воспитании. – Казан: Татар. кит нәшр., 2021. – 223 б.: портр. б-н. – Текст парал.: татар., рус.

**Насыйри К.** Китаб әт-тәрбия = Книга о воспитании / мөхәррир һәм кереш сүз авт. **Ә.Р.Сабыр.** – Казан: Иман, 2024. – 247 б. – Текст парал.: татар., рус.

**Насыйри К.** Әбүгалисина: балалар өчен кыйсса. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 118 б.: рәс.

**Насыйри К.** Халык иҗаты әсәрләре, татар этнографиясе материаллары / төз. Р.Г.Мөхсинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. – 318 б.

**Насыйри К.** Шифалы үләннәр Хәвасе

нәбатат. – Казан: Раннур, 1999. – 192 б. – («Юлдаш» китапханәсе).

**Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри** / Академия наук СССР, Казанский филиал; авт. предислов. А.Н.Кононов. – Казань: Казанский ин-т языка, литературы и истории, 1976. – 214 с.

**Абдуллин Я.** Каюм Насыри // История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX вв.). – Казань: Фикер, 2003. – С. 99–110.

**Яковлева Е.Л.** Возвращение к истокам: Каюм Насыри в оптике современности: философский триптих о татарском Леонардо да Винчи. – Казань: Познание, 2016. – 156 с.: ил. – (Сокровищница Татарстана).

**Мифтахова Н.Ш.** Химия в просветительской деятельности Каюма Насыри: монография / М-во науки и высшего образования РФ; Казанский национальный исследовательский технолог. ун-т. – Казань: Изд-во КНИТУ, 2023. – 225 с.

**Фахрутдинов Р.З.** Естественно-математическое образование в педагогическом наследии Каюма Насыри. – Казань: Изд-во КГУ, 2005. – 122 с.

**Юзеев А.Н.** Просветительская мысль татарского народа (XIX – нач. XX вв.): монография. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. – 415 с. – Просетительские аспекты мировоззрения К.Насыри (2-я пол. 50-х гг. XIX – нач. XX в.). – С. 284–300.

**Каюм Насыйри: әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык** / [фәнни мөх-ре Ж. Миңнуллин; төз. Р.Исламов]. – Казан: Жыен, 2017. – 815 б.: + [16] б. фоторәс. – (Шәхесләребез = Знаменитые личности). – Библиогр.: б. 755–811.

**Шәфигуллина Р.** Каюм Насыйри // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т. 3: XIX гасыр. – 2 нче басма, яңарт. һәм тулыл. – Казан: Татар кит. нәшр., 2023. – Б. 193–199.

**Гайнуллин М., Гайнетдинов М., Мәхмүтов Х. Каюм Насыйри** // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т.3: XIX гасыр. – Казан: Татар кит. нәшр., 2015. – Б. 229–241.

**Батыршина Г.Г.** Каюм Насыйриның лексикографик эшчәнлеге. – Казан: [КДАТУ нәшр.], 2007. – 171 б.

**Насыйри укулары – Насыровские чтения: материалы Первой межрегиональной науч. конф. с международным участием** (24–25 февраля 2022 г.). – Казань, 2022. – 243 с., [56] вкл. л. цв. фот.: ил., фот., табл. – Текст на рус., татар. яз.

**Каюм Насыйри музее: буклет = Музей Каюма Насыри** / Татарстан Республикасы Милли музее; татар теленә тәрҗ. Л.Р.Таҗиева; фәнни концепциясе авт. Р.С.Хөснетдинова. – Казан: Заман, 2002. – 24 б. – На татар. и рус. яз.

**Мәгърифәтчелек каһарманы: Каюм Насыйри: Каюм Насыйриның (1825–1902) тууына 180 ел: күргәзмә каталогы, 2005 ел, янв.–февр.** / ТР Милли к-ханәсе; [төз.З.А.Мамакова]. – Казан: Милли китап, 2005. – 27 б. – Татар һәм рус телләрендә.

**Мусабәкова Р.** Каюм Насыри // Кырык татар=Сорок татар=The Forty Tatars / Бөтендөнья язучылар ассоциациясе (Халыкара ПЕН-клуб). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – Б.225–233. – Татар, рус, ингл. тел.

**Заһидуллин И.** Насыйри – рус-татар мәктәбе укытучысы // Казан утлары. – 2024. – № 11. – Б. 177–184.

## 29 мая / май



### Абрар Каримуллин
### Әбрар Кәримуллин

**1925–2000**

**100 лет со дня рождения**
**тууына 100 ел**

Академик Абрар Гибадуллович Каримуллин родился 29 мая 1925 года в деревне Чабья-Чурчи Сабинского района Республики Татарстан в семее крестьянина. В 1941 году окончил среднюю школу с. Богатые Сабы. Работал в колхозе, бухгалтером в больнице, учителем.

В 1943–1947 годах служил в рядах Советской Армии, участвовал в сражениях Великой Отечественной войны.

С 1948 по 1953 год – студент отделения татарской филологии Казанского государственного университета, после окончания которого А.Каримуллин работает в Научной библиотеке Казанского университета.

Работая в библиотеке, знакомясь с его фондами, А.Каримуллин обнаруживает богатство татарской старопечатной книги. Под его руководством проводится рекаталогизация татарских книг на арабском шрифте. А.Г.Каримуллин приступает к созданию научных отраслевых библиографических указателей по татарской литературы, истории литературы, литературоведению, языкознанию, фольклору, истории Татарстана, некоторые из которых издаются отдельными книгами. Именно с них началось становление татарской научной библиографии и научной библиографии Татарстана. В эти же годы налаживается работа по пополнению фондов библиотеки старыми рукописными книгами.

С декабря 1964 года А,Г.Каримуллин работает в Институте языка, литературы и истории им. Г.Ибрагимова, занимается изучением истории татарской старопечатной книги, защищает по этому научному направлению кандидатскую и затем докторскую диссертации.

С выходом монографии «Татарская книга пореформенной России» завершается воссоздание истории татарской книги дореволюционного периода.

А.Г.Каримуллин – учёный широкого профиля. Он впервые воссоздаёт историю татарской книги, впервые составляет национальную библиографию по филологии, истории искусства, персоналий известных учёных и писателей родного края.

В Национальной библиотеке Республики Татарстан А.Г.Каримуллин возглавляет работу по созданию «Сводного каталога татарской старопечатной книги: 1722–1917 гг.».

Учёный уделяет большое внимание национальному возрождению татарского народа, его языка, культуры, современной общественно-политической жизни республики.

Научная и общественная деятельность А.Г.Каримуллина получают признание как в нашей стране так и зарубежом. Ему присвоено звание «Заслуженный деятель науки Татарстана», он – лауреат Государственной премии Татарстана им. Г.Тукая, удостоен ряда почётных грамот и медалей, почётных званий научных обществ ряда зарубежных стран.

А.Г.Каримуллин умер 18 сентября 2000 года.

---

Академик Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин 1925 елның 29 маенда Татарстан Республикасының Саба районы Чәбия-Чүрчи авылында крестьян гаиләсендә туа. 1941 елда Саба урта мәктәбен тәмамлаганнан соң

хезмәт юлын башлый: колхозчы, хисапчы, укытучы булып эшли. 1943–1947 елларда Ә.Кәримуллин Совет Армиясе сафларында хезмәт итә, Бөек Ватан сугышы фронтлары буйлап сугышчан юл уза.

1948–1953 елларда Ә.Кәримуллин – Казан дәүләт университеты студенты. Тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң ул университетның Фәнни китапханәсендә эшләргә калдырыла. Беренче эш итеп ул иске татар китапларының каталогын төзи башлый, татар теле һәм тел белеме, әдәбият тарихы һәм әдәбият белеме, фольклор, Татарстан тарихына караган фән тармакларында аерым библиографик күрсәткечләр төзүгә керешә. Болар барысы да татар һәм Татарстан фәнни библиографиясенең оешу башлангычын, аның нигезен тәшкил итә. Шул ук вакытта бу елларда китапханә фондын иске кулъязма китаплар белән тулыландыру да җайга салына.

1964 елның декабреннән Ә.Кәримуллин Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли, «Татарларда матбагачылык туу һәм татар филологиясе буенча яңа чыганаклар» дигән темага кандидатлык, «XX гасыр башы татар китабы» дигән хезмәте нигезендә докторлык диссертациясе яклый. 1983 елда Ә.Кәримуллинның «Реформадан соңгы Россиядә татар китабы» дип исемләнгән яңа монографиясе китап булып басыла. Татар китабының революциягә кадәрге чорын яктырткан трилогия тарихи яктан бер бөтенлек ала.

Әдәби тәнкыйтьче сыйфатында да Ә.Кәримуллин гаять актив эшли. Ул дистәләгән әдип, галимнәребезнең библиографияләрен хәзерли. Галим Татарстан Милли китапханәсендә искебасма татар китапларының (1722–1917 еллар) җыелма каталогын төзү эше белән җитәкчелек итә. Ә.Кәримуллин татар халкы язмышы, халкыбызның бүгенге һәм киләчәк тормышы хакында кыю мәкаләләр яза, китаплар чыгара, татар халкын милләт буларак саклауга үзеннән зур өлеш кертә.

Ә.Кәримуллин – Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Хезмәтләре үзебездә дә, чит илләрдә дә киң мәгълүм. Ул бик күп чит ил фәнни оешмаларының мактау кәгазьләре, медальләре, мактаулы титул һәм исемнәре белән бүләкләнгән.

Ә.Г.Кәримуллин 2000 елның 18 сентябрендә вафат була.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:

**Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин =Абрар Гибадуллович Каримуллин=Abrar Gibadullovich Karimullin: биобиблиогр. күрсәткеч** /[төз. А.Ф.Мәхмүтова; фәнни мөхре Т.Г.Дунаева]. – Казан: Милли китап, 2011. –272 б. – («Татар әдипләре» сер.).

**Каримуллин А.Г.** У истоков татарской книги (от начала возникновения до 60-х годов XIX века). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1971. – 224 с.

**Каримуллин А.** Татарская книга начала XX века. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. – 319 с.

**Каримуллин А.** Татарская книга пореформенной России: исследование. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. – 320 с.

**Каримуллин А.** Книги и люди: исследование. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. – 304 с.

**Каримуллин А.Г.** Татары: этнос и этноним. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. – 126 с.

**Каримуллин А.Г.** Прототюрки и индейцы Америки: по следам одной гипотезы / [вступ. ст. Я.Гибадуллина]. – М.: ИНСАН, 1995. – 80 с.

**Каримуллин А.Г.** Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917–1932). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1999. – 320 с.

**Кәримуллин Ә.** Китап дөньясына сәяхәт: татар басма сүзенең сәхифәләреннән. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 208 б.

**Кәримуллин Ә.** Татарлар: исемебез һәм җисемебез. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 160 б.

**Кәримуллин Ә.** Татар фольклоры: аннотацияләнгән әдәбият күрсәткече (1612–1981). Ике кисәктә / ТФА. Г.Ибраһимов исем. ТӘТИ. – Казан, 1993.

1 кис. – 135 б.
2 кис. – 134 б.

**Кәримуллин Ә.** Язмыш, язмыш... / [кереш сүз язучы Р.Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996.– 423 б.

**Кәримуллин Ә.** Тел – милләтнең сакчысы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 256 б.

**Кәримуллин Ә.** Без тарихта эзлебез. – Казан: Милли китап, 2000. – 464 б.: портрт. б-н.

**Кәримуллин Ә.** Безнең кардәшлек: мәкаләләр / [кереш сүз язучы Р.И.Вәлиев]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 335 б.: портрт. б-н.

**Академия наук Татарстана.** – Казань: Фән, 1992. – 304 с. – Абрар Гибадуллович Каримуллин. – С. 35–37.

**Валеев Р.И.** Верный рыцарь книги // Респ. Татарстан. – 2000. – 26 мая.

**Баренбаум И.** «Книга – путь к душе...» // Идель. – 2000. – № 7. – С. 54–57.

**Гаффар А.** Жажда истины. Абрар Каримуллин // Казань. – 2001. – № 12. – С. 42–43.

**Халиуллин Й.** Ум и совесть татарской науки // Татарстан. – 2003. – № 8. – С. 49–53.

**Әдипләребез: биобиблиогр. белешмәлек. 2 томда.** Т.1 /[төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 735 б. – Әбрар Кәримуллин. – Б. 713–714.

**Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары:** биобиблиогр. белешмә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 639 б. – Әбрар Кәримуллин. – Б. 273–275.

**Татарстан Фәннәр Академиясе.** – Казан: Фән, 1994. – 544 б. – Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин. – Б. 47–49.

**Галимуллин Ф.** Галимне искә алганда // Мәйдан. – 2023. – № 7. – Б.102–112.

**Һадиев И., Асылкаева Н.** Татар фәне тарихында эзе тирән // Казан утлары. – 2005. – № 6. – Б. 173–177.

**Низамов И.** Яңа фәнгә бер өлеш // Мәдәни җомга. – 2000. – 26 май. – Б. 12–13.

**Бәйрәмова Ф.** Әбрар Кәримуллин бүген дә тел сагында //Мәдәни җомга. – 2018. – 14 июнь. – Б. 16; 22 июнь. – Б. 14.

**Фәйзрахманов Ә.** Яшәү мәгънәсе // Мәдәни җомга. – 2020. – 29 май. – Б. 16–17.

## 17 июня / июнь



### Пётр Михайлович Гаврилов

**1899–1992**

**125 лет со дня рождения**
**тууына 125 ел**

Герой Советского Союза, майор Пётр Михайлович Гаврилов родился 17 июня 1900 года в селе Альвидино Лаишевского уезда Казанской губернии (ныне Пестречин-

ский район Республики Татарстан) в семье крестьянина из крещёных татар. Рано лишившись отца, с детства познаёт нищету и тяготы. Он оканчивает Казанскую центральную крещёно-татарскую школу.

В 15 лет Пётр пешком отправляется в Казань, работает чернорабочим, участвует в Октябрьском вооружённом восстании. В начале 1918 года добровольцем вступает в ряды Красной Армии, сражается на фронтах гражданской войны, сначала с чехословацким корпусом, затем с войсками адмирала Колчака и генерала Деникина. После окончания войны остаётся в армии во Владикавказе, избирает профессию кадрового военного.

В сентябре 1925 года П.М.Гаврилов заканчивает Владикавказскую пехотную школу, в 1939 году Военную академию имени М.В.Фрунзе.

Участвует в советско-финской войне 1939–1940 годов.

С первых дней Великой Отечественной войны он в действующей армии.

Командир 44-го стрелкового полка 42-й стрелковой дивизии, 13-й армии Западного фронта майор П.М.Гаврилов с 22 июня по 23 июля 1941 года руководит обороной Восточного форта Брестской крепости. Он показывал бойцам пример бесстрашия и мужества. Ему удалось сплотить вокруг себя всех уцелевших бойцов и командиров разных частей и подразделений, закрыть наиболее уязвимые места для возможного прорыва врага.

23 июля от взрыва снаряда в каземате П.М.Гаврилов получает тяжёлое ранение и в бессознательном состоянии был пленён. Годы войны проводит в гитлеровских концлагерях, испытав все ужасы плена.

Освобождается советскими войсками в мае 1945 года. После освобождения из немецкого плена П.М.Гаврилов был отправлен в фильтрационный лагерь на Дальнем Востоке. Проверку закончили к июню 1946 года.

После демобилизации в июле 1946 года он возвращается на родину. Через год переезжает в Краснодар.

Указом Президиума Верховного Совета СССР от 3 января 1957 года за образцовое выполнение воинского долга при обороне Брестской крепости и проявленные при этом отвагу и героизм Петру Гаврилову присвоено звание Героя Советского Союза с вручением ордена Ленина и медали «Золотая Звезда». Он – Почётный гражданин Бреста (Белоруссия).

Впоследствии Пётр Михайлович много ездил по стране, все знания и силы отдавал военно-патриотическому воспитанию молодёжи, активно занимался общественной работой.

Пётр Михайлович Гаврилов умер 26 января 1979 года и по его завещанию был с воинскими почестями погребён на гарнизонном кладбище Бреста.

Именем Петра Гаврилова названы улицы в городах Казани, Бресте, Краснодаре, Иркутске и Пестрецах. В 2010 году в деревне Альвидино к 110-летию со дня рождения П.М.Гаврилова был открыт музей. В 2020 году барельеф Героя установлен на аллее Славы работников порохового завода в парке имени Р.Петрова Казани. 22 июня 2022 года в Пестречинском районе Татарстана открыт бюст Героя Советского Союза Петра Михайловича Гаврилова.

Советлар Союзы Герое, майор, керәшен татары Пётр Михайлович Гаврилов 1900 елның 17(30) июнендә Казан губернасының Лаеш өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Питрәч районы) Әлбәдән авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Әтисез калып, ба-

ла чактан ук тормышның авырлыгын күрә. Ул Казан үзәк керәшен-татар мәктәбен тәмамлый.

Унбиш яшлек Пётр җәяүләп Казанга килә, кара эшче булып эшли, Октябрь коралды восстаниесендә катнаша. 1918 ел башында үз теләге белән Кызыл Армия сафларына баса, гражданнар сугышы фронтларында: башта Чехословакия корпусы, аннары адмирал Колчак һәм генерал Деникин гаскәрләре белән сугыша. Сугыш тәмамланганнан соң Владикавказда армиядә кала, кадровый хәрби һөнәрен сайлый.

1925 елның сентябрендә П.М.Гаврилов Владикавказда пехота мәктәбен, 1939 елда М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академияне тәмамлый.

1939–1940 еллардагы совет-фин сугышында катнаша.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк ул хәрәкәттәге армиядә.

44 нче укчы полкның (Көнбатыш фронтның 13 нче армиясе, 42 нче укчы дивизия) командиры майор П.М.Гаврилов 1941 елның 22 июненнән 23 июлено кадәр Брест крепостеның Көнчыгыш форты оборонасына җитәкчелек итә. Ул сугышчыларга куркусызлык һәм батырлык үрнәген күрсәтә. Төрле частьләр һәм подразделениеләрдән исән калган сугышчыларны һәм командирларны үз тирәсенә туплый ала. Алар дошман үтеп керү мөмкин булган юлларны биклиләр.

23 июльдә казаматта снаряд кыйпылчыгы тиеп, каты яраланган һәм аңын югалткан хәлдә П.М.Гаврилов фашистларга әсирлеккә эләгә. Сугыш елларын Гитлер концлагерьларында үткәрә, әсирлекнең барлык ачысын татырга туры килә.

1945 елның маенда совет гаскәрләре тарафыннан азат ителә. Немец әсирлегеннән азат ителгәннән соң П.М.Гаврилов Ерак Көнчыгыштагы фильтрацион лагерьга җибәрелә. Тикшерүне 1946 елның июненә тәмамлыйлар.

1946 елның июлендә демобилизацияләнгәннән соң, ул туган ягына кайта. Бер елдан Краснодарга күчеп китә.

СССР Югары Советы Президиумының 1957 елның 3 гыйнварындагы Указы нигезендә Брест крепосте оборонасында хәрби бурычны үрнәк рәвештә үтәгән һәм шул ук вакытта кыюлык һәм каһарманлык күрсәткән өчен Пётр Гавриловка Советлар Союзы Герое исеме бирелә, Ленин ордены һәм «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла. Ул – Брестның (Белоруссия) Мактаулы гражданины.

Соңыннан Пётр Михайлович ил буйлап күп йөри, яшьләрне хәрби-патриотик рухта тәрбияләүгә бөтен белемен һәм көчен бирә, актив җәмәгать эше алып бара.

Пётр Михайлович Гаврилов 1979 елның 26 гыйнварында вафат була һәм үзенең васыяте буенча Брестның гарнизон зиратына хәрбиләрчә хөрмәтләп җирләнә.

Казан, Брест, Краснодар, Иркутск шәһәрләрендә, Питрәчтә Пётр Гаврилов исеме белән урамнар аталган. 2010 елда Әлбәдән авылында П.М.Гавриловның тууына 110 ел тулу уңаеннан музей ачыла. 2020 елда Казанның Р.Петров паркында, дары заводы хезмәткәрләренең Дан аллеясында Геройның барельефы урнаштырыла. 2022 елның 22 июнендә Татарстанның Питрәч районында Советлар Союзы Герое Пётр Михайлович Гавриловның бюсты куела.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:

**Гаврилов П.М.** Сражается крепость. – Краснодар: Кн. изд-во, 1975. – 94 с.

**Гаврилов П.М.** Сражается крепость: докум. повесть / [лит. запись А.И.Макаренко]. – 2-е изд., испр. и доп.– Краснодар: Кн. изд-во, 1980. – 142 с.: ил.

**Гаврилов П.М.** Крепость көрәшә: докум. повесть / Ә.Хәсәнов тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 159 б.

**Марихин Б.** Гаврилов Пётр Михайлович // Герои Советского Союза – наши земляки: (сб. докум. очерков и зарисовок в 3-х кн.). Кн.1. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. – С. 99–101.

**Аскарова Л.Р.** Майор Гаврилов из Пестрецов – защитник Брестской крепости // Махмут Гареев: военный, учёный и общественный деятель (к 100-летию со дня рождения): сб. статей Всероссийской науч. конф., Казань, 20–21 июня 2023 года. – Казань: Институт Татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, 2023. – С. 189–195.

**Матылицкий В.** Последний бой комполка // Татарстан. – 2015. – № 5. – С. 38–41.

**Амиров К.Ф.** Казанских улиц имена / К.Ф.Амиров, Р.Х.Ахметзянова, Р.Г.Вениаминов. – Казань: Центр инновационных технологий, 2008. – 589 с. – Гаврилова. – С. 120–121.

**Мусабәкова Р.** Пётр Гаврилов // Кырык татар=Сорок татар=The Forty Tatars / Бөтендөнья язучылар ассоциациясе (Халыкара ПЕН-клуб). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – Б. 46–51. – Текст татар., рус., ингл. тел.

**Марихин Б.** Гаврилов Пётр Михайлович // Советлар Союзы Геройлары – якташларыбыз: әдәби докум. очерклар һәм язмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – Б. 84–86.

**Батырлар китабы = Книга Героев.** – Казан: Татар. китап нәшр., 2000. – 395 б., портр. – Гаврилов Пётр Михайлович. – С. 84. – Текст парал. татар һәм рус тел.

**Кәримуллин Р.** Гавриловны без дә беләбез // Ватаным Татарстан. – 2014. 6 авг. – Б. 5.

**Алимов А.** Арагызда татарлар юкмы ? // Ватаным Татарстан. – 2016. – 18 июнь. – Б. 5.

**Бәдретдинов Х.** Соңарып килгән танылу // Мәдәни җомга. – 2020. – 8 май. – Б. 4.

**Кашапова С.** Әлбәдәндә Герой яшәгән // Мәдәни җомга. – 2022. – 6 май. – Б. 5.

## 11 июля / июль



## Алмаз Монасыпов
## Алмаз Монасыйпов

**1925–2008**

**100 ЛЕТ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ**
**ТУУЫНА 100 ЕЛ**

Композитор Алмаз Закирович Монасыпов родился 11 июля 1925 года в Казани. В его семье часто звучала музыка, а отец любил играть на скрипке. Алмаз в детстве и юности занимался по классу виолончели у преподавателя Р.Л.Полякова в Казанской музыкальной школе, а затем в Казанском музыкальном училище.

В 1942 году он – артист оркестра Театра оперы и балета в Казани; в 1942–1943 годах – артист Квартета Татарской филармонии.

В 1943 году А.Монасыпов был призван в ряды Советской Армии, участвовал в Великой Отечественной войне. После войны поступил в Казанскую государственную консерваторию, которую завершил дважды: по классам виолончели у А.Броуна (1950) и композиции у А.Лемана (1956). В 1964 году окончил аспирантуру консерватории по специальности «оперно-симфоническое дирижирование» в

классе профессора И.Шермана.

В 1959–1970 годах А.Монасыпов работает дирижёром Татарского государственного театра оперы и балета имени М. Джалиля. С 1970 по 1972 год был дирижёром симфонического оркестра Татарской государственной филармонии; с 1968 по 1972 год – преподавателем в Казанской консерватории по классу композиции.

С 1972 года А.Монасыпов живёт в Москве, но активно участвует в музыкальной жизни Республики Татарстан, в работе Союза композиторов Татарстана и в воспитании молодых композиторов.

Уже в ранних сочинениях Алмаз Монасыпов стремится к поиску своего оригинального стиля, к созданию серьёзных по замыслу произведений. Композитор ярко проявляет себя в жанре симфонии. Большой успех принесла ему симфония-поэма «Муса Джалиль».

Алмаз Монасыпов – признанный композитор-симфонист, мастер большой формы, глубокой концепции. Четыре симфонии, симфонические поэмы «Бәйрәм бүген» («Сегодня праздник!») и «Идель-йорт», «Салих Сәйдәшевкә музыкаль бүләк» («Музыкальное приношение Салиху Сайдашеву») открыли новую страницу национального симфонизма.

Особое место в творчестве композитора занимает вокально-симфоническая поэма «Тукай аһәңнәре» («Мелодии Тукая»), в которой сочетаются оригинальный музыкальный язык автора, интонация татарских народных песен, выразительные восточные мотивы и ритмы, элементы джазовой стилистики и необычные инструменты. Монасыпов значительно расширяет область традиционной интонации татарской музыки.

В музыке композитора органично сплелись выразительные восточные мотивы и тематика татарских народных песен, элементы джаза и интонации древних баитов. Богатейшая интонационная гармоническая, тембровая палитра творчества А.Монасыпова обогатила современную татарскую музыку новыми свежими красками. Наряду с восточными, в творчестве композитора особое значение приобретают европейские традиции.

Алмаз Монасыпов проявил себя как мастер создания больших симфонических форм, внося глубокий смысл в новые темы, используя новые приёмы обработки музыкального материала. Его произведения глубоко концептуальны по содержанию, вызывают множество ассоциаций. Он оставил богатое творческое наследие. Им были созданы произведения в разнообразных жанрах: симфонические и камерно-инструментальные произведения, популярные романсы и песни, музыка к драматическим спектаклям.

За деятельность в области музыкальной культуры А.Монасыпов удостоен званий: заслуженного деятеля искусств ТАССР (1969), РСФСР (1987), лауреата Государственной премии Татарстана имени Г. Тукая (1991), народного артиста Республики Татарстан (2000).

Многосторонняя творческая и исполнительская деятельность А.Монасыпова является бесценным вкладом в культуру и искусство России и Республики Татарстан.

Алмаз Закирович Монасыпов умер 22 июля 2008 года в Москве. Похоронен на Митинском кладбище.

Композитор Алмаз Закир улы Монасыйпов 1925 елның 11 июлендә Казан шәһәрендә туа. Аларның гаиләсендә еш кына музыка яңгырый, ә әтисе скрипкада уйнарга ярата торган була. Алмаз башта Казан музыка мәктәбендә, аннары Казан музыка училищесында Р.Л.Поляковның виолончель классында укый.

1942 елда ул – Казанда Татар опера һәм балет театры оркестрында артист; 1942–1943 елларда – Татар филармониясендә квартет артисты була.

1943 елда А.Монасыйпов Совет Армиясе сафларына алына, Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң Казан дәүләт консерваториясенә укырга керә, аны ике тапкыр: 1950 елда А.Броунның виолончель классы һәм 1956 елда А.Леманның композиция классы буенча тәмамлый. 1964 елда профессор И.Шерман классында «опера-симфоник дирижёрлау» белгечлеге буенча консерватория аспирантурасын тәмамлый.

1959–1970 елларда А.Монасыйпов М.Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театрында дирижёр булып эшли. 1970–1971 елларда Татар дәүләт филармониясенең симфоник оркестры дирижёры; 1968–1972 елларда Казан консерваториясендә композиция классында укытучы була.

1972 елдан А.Монасыйпов Мәскәүдә яши, әмма Татарстан Республикасының музыка тормышында, Татарстан Композиторлар берлеге эшендә һәм яшь композиторларны тәрбияләүдә актив катнаша.

Беренче язмаларында ук Алмаз Монасыйпов үзенең оригиналь стилен табарга, җитди әсәрләр иҗат итәргә омтыла. Композитор үзен симфония жанрында ачык күрсәтә. «Муса Җәлил» симфоник поэмасы аңа зур уңыш китерә.

Алмаз Монасыйпов – танылган композитор-симфонист, зур форма, тирән концепция остасы. Бу жанрга караган 4 симфониясе, «Бәйрәм бүген!» һәм «Идел-йорт», «Салих Сәйдәшевкә музыкаль бүләк» симфоник поэмалары милли симфониянең яңа сәхифәләрен ача.

Композитор иҗатында «Тукай аһәңнәре» вокаль-инструменталь поэмасы аерым урын тота, анда авторның оригиналь музыка теле, татар халык җырлары интонациясе, Шәрекъ мотивлары һәм ритмнарының тәэсирлелеге, джаз стилистикасы элементлары һәм гадәти булмаган инструментарий бергә үрелгән. Монасыйпов татар музыкасының традицион интонация өлкәсен шактый киңәйтә.

Композиторның музыкасында көнчыгышның сәнгатьле мотивлары белән татар халык җырларының тематикасы, джаз элементлары һәм борынгы бәетләрнең интонациясе органик рәвештә бер-берсенә үрелеп бара. А.Монасыйповның бай интонацион гармонияле, тембрлы иҗат палитрасы заманча татар музыкасын яңа төсләр белән баета. Композитор иҗатында Шәрекъ элементлары белән беррәттән Европа традицияләре дә аерым урын алып тора.

Алмаз Монасыйпов, яңа темаларга тирән мәгънә салып, музыкаль материалны эшкәртүдә яңа алымнар кулланып, үзен зур симфоник формалар иҗат итү остасы буларак таныта. Аның әсәрләре эчтәлеге ягыннан тирән концептуаль, күптөрле ассоциацияләр тудыра. Ул бай иҗади мирас калдыра. Аның тарафыннан төрле жанрларда: симфоник һәм камера-инструменталь әсәрләр, популяр романслар һәм җырлар, драматик спектакльләргә музыка иҗат ителә.

Музыка мәдәнияте өлкәсендәге эшчәнлеге өчен А.Монасыйпов мактаулы исемнәргә лаек була: ТАССРның (1969), РСФСРның (1987) атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1991), Татарстан Республикасының халык артисты (2000).

А.Монасыйповның күпьяклы иҗади һәм башкару эшчәнлеге Россия һәм Татарстан Республикасы мәдәниятенә һәм сәнгатенә керткән бәяләп бетергесез өлеш булып тора.

Алмаз Закир улы Монасыйпов 2008 елның

22 июлендә Мәскәүдә вафат була. Шәһәрнең Митино зиратында күмелә.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:


**Монасыпов А.З.** Симфония-поэма «Муса Джалиль» [ноты] = Symphony-poem «Mussa Jalil». – Партитура. – М.: Сов. композитор, 1973. – 70 с.

**Монасыпов А.** Третья симфония: для большого симф. орк. – Партитура. – М.: Сов. композитор, 1977. – 120 с.

**Монасыпов А.** Мозаика: десять пьес для фп. – М.: Сов. композитор, 1979. – 16 с.

**Монасыпов А.З.** Четвёртая симфония (дастан) [ноты] = Fourth symphony: [для большого симфонического оркестра]. – М.: Сов. композитор, 1983. – 64 с.

**Монасыпов А.** А любовь-то лебедем [ноты]: песни для голоса в сопровождении фортепиано (гитары). – М.: Сов. композитор, 1985. – 68 с.

**Монасыйпов А.** Хыяллар [ноталар]: эстрада өчен җырлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. – 44 б.: ноталар белән.

**Монасыйпов А.** Тамчылар [ноталар]: [җырлар, романслар]. – [Казан: Татар. кит. нәшр., 1985]. – 64 б.: ноталар белән.

**Монасыпов А.** Неразрывная связь: [воспоминания композитора] // Казань. – 2005. – № 5. – С. 18–19.

**Монасыпов А.** Родился в рубашке / беседовал А.Малахальцев // Респ. Татарстан. – 2005. – 21 июля.

**Алмазова А.** Алмаз Монасыпов // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – С. 102–105.

**Губайдуллина Г.** Алмаз Монасыпов // Звуковое пространство композиторов Татарстана: Очерки. Интервью. Восломининия. – Казань: Музыка России, 2014. – С. 190–192.

**Губайдуллина Г.** Родное в памяти и сердце // Казань. – 2005. – № 6 – С. 73–77.

**Алмазова А.** Открывая новые горизонты // Науч. Татарстан. – 2000. – № 3. – С. 64–69.

**Шарифуллина Н.** Весна в Сухуми // Казань. – 2005. – № 10. – С. 37–40.

**Щербакова Р.** Монасыповская вольница: [о династии Монасыповых] // Респ. Татарстан. – 2003. – 14 марта. – С. 13.

**Алмазова А.** Татар музыкасын яңартучы // Казан утлары. – 2015. – № 9. – Б. 184–186.

**Алмазова А.А.** Яңалыкка юл яру // Фәнни Татарстан. – 2000. – № 3. – Б.47–52.

**Гобәйдуллина Г.** Җыр-моң белән үрелгән гомер // Казан утлары . – 2005. – № 11. – Б. 110–113.

**Гыйматдинова Н.** Моң патшасы // Сәхнә. – 2015. – № 7. – С. 16–18.

**Шәрифуллина Н.** Зур иҗат балкышлары // Казан утлары. – 2000. – № 10. – Б. 156–164.

**Шәрифуллина Н.** Көйгә әверелгән хыяллар // Мәдәни җомга. – 2006. – 14 июль. – Б. 11.

**Хәбибуллина Л.** Кояшларың белән кер син гомер көзләреңә // Шәһри Казан. – 2005. – 23 дек.

## 22 июля / июль



### Хамид Музаффарович Муштари
### Хәмит Мозаффар улы Мөштәри

**1900–1981**

**125 лет со дня рождения**
**тууына 125 ел**

Выдающийся татарский учёный-математик, первый татарский доктор физико-математических наук, профессор Хамид Музаффарович Муштари родился 22 июля 1900 года в городе Оренбурге, в семье учителя. Первоначальное образование он получает в школе при приюте, затем во 2-ой гимназии для мальчиков в Казани. В 1918 году он с золотой медалью заканчивает гимназию и в том же году поступает на физико-математический факультет Казанского университета. В 1920 году по состоянию здоровья переводится в Среднеазиатский университет города Ташкента. Закончив университет в 1923 году, Муштари возвращается в Казань.

В 1925 году Х.Муштари поступает в аспирантуру Московского университета. Его научный руководитель, всемирно прославленный академик С.А.Чаплыгин, ставит перед ним задачу наиболее углублённого изучения математики, физики, механики. В 1929 году он защищает кандидатскую диссертацию, и с этого года вся научная и педагогическая деятельность Х.Муштари связана с Казанью. Он долгие годы заведует кафедрой теоретической механики Казанского института инженеров коммунального строительства, Казанского авиационного института, позже Казанского химико-технологического института.

В 1934–1938 гг. Х.Муштари закладывает основы нелинейной теории тонких оболочек, в 1938 году по этой теме защищает докторскую диссертацию в Московском университете. Многие труды Х.М.Муштари посвящены дальнейшему развитию этой теории и использованию её в решении важных практических задач. Им выполнен также ряд других исследований, имеющих важное теоретическое и прикладное значение.

С 1946 по 1972 годы Муштари является директором физико-технического института Казанского филиала АН СССР и до 1976 года возглавляет отдел теории оболочек этого института.

Хамидом Музаффаровичем написано свыше ста работ, вошедших в золотой фонд механики. Он создаёт известную научную школу, воспитав 8 докторов и более 30 кандидатов наук.

Заслуги Х.М.Муштари были высоко оценены: он был награждён орденами Ленина, Трудового Красного Знамени, Знака Почёта и медалями, ему присвоены почётные звания заслуженного деятеля науки и техники ТАССР и РСФСР.

Х.М.Муштари умер 23 января 1981 года. Похоронен на Новотатарском кладбище в городе Казани.

В Казани имя известного учёного увековечено. Именем Хамида Муштари названа улица в Вахитовском районе города. Мемориальные доски в память об учёном были установлены в Казани на доме № 30 по улице, носящей его имя, в котором он жил в 1945–1981 годах; в фойе здания Физико-технического института Казанского научного центра Российской академии наук.

Хәмит Мозаффар улы Мөштәри – татарлар арасында беренче физика-математи-

ка докторы, профессор – 1900 елның 22 июлендә Оренбург шәһәрендә, мөгаллим гаиләсендә туа. Ул башта приют каршындагы мәктәптә, соңрак Казанның 2 нче ир балалар гимназиясендә укый. 1918 елда гимназияне алтын медальгә тәмамлый.

Мөштәри 1918 елда Казан университетының физика-математика факультетына укырга керә. Әмма, сәламәтлеге какшау сәбәпле, 1920 елда Ташкент шәһәрендәге Урта Азия университетына күчә. Университетны 1923 елда тәмамлаганнан соң, ул яңадан Казанга кайта.

1925 елда Мөштәри Мәскәү университетының аспирантурасына укырга керә. Дөньякүләм танылган академик С.А.Чаплыгин, фәнни җитәкчесе буларак, аның алдына математика, физика, механика фәннәрен тирәнтен өйрәнү бурычын куя. 1929 елда ул кандидатлык диссертациясен яклый һәм, шушы елдан башлап, Мөштәринең фәнни һәм педагогик эшчәнлеге тулысынча Казан белән бәйләнгән. Ул Казан коммуналь төзелеш институтының теоретик механика кафедрасын, Казан авиация институтының теоретик механика һәм эластиклык теориясе кафедрасын, соңрак Казан химия-технология институтының теоретик механика кафедрасын җитәкли.

1934–1938 елларда ул юка тышчаларның нәсызыкча теориясенә нигез сала, ә 1938 елда Мәскәү университетында шушы теориягә багышланган гыйльми эшләре буенча докторлык диссертациясен яклый.

1946–1972 елларда Х.Мөштәри СССР ФА Казан филиалының физика-техника институты директоры була, шуның белән бергә, 1976 елга кадәр шушы институтның тышчалар теориясе бүлеген җитәкли.

Х.Мөштәри бик күп шәкертләр тәрбияли, алар арасында 8 фән докторы, 30 дан артык фән кандидаты бар.

Х.Мөштәри 100дән артык гыйльми хезмәт яза, аның хезмәтләре югары бәяләнә. Ул Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы, Мактау Билгесе орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә, Россиянең һәм Татарстанның атказанган фән һәм техника эшлеклесе дигән мактаулы исемнәргә лаек була.

Х.Мөштәринең нәсызыкча механикасы буенча язган хезмәтләре безнең илдә генә түгел, чит илләрдә дә яхшы мәгълүм. Аларда булган идеяләр бүген дә әһәмиятен югалтмыйлар.

Х.Мөштәри 1981 елның 23 гыйнварында вафат була.

Казанда күренекле галимнең исеме мәңгеләштерелгән. Шәһәрнең Вахитов районындагы бер урам Х.Мөштәри исемен йөртә. Казанда, Х.Мөштәри 1945–1981 елларда яшәгән йортта (Х.Мөштәри урамы, 30), Россия фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең Физика-техника институты бинасының фойесында галим истәлегенә мемориаль библиотекалар... 

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:

**Муштари Х. М.** Нелинейная теория оболочек: сборник научных трудов / Академия наук СССР, Казанский научный центр, Казанский физико-технический институт. – М.: Наука, 1990. – 224 с.

**Ильгамов М.А.** Профессор Х.М.Муштари. – М.: Наука. Физматлит, 2001. – 192 с.

**Хамид Музафарович Муштари: 1900–1981** / сост., научный редактор Ю. Г. Коноплёв. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2004. – 37 с. – (Выдающиеся учёные Казанского университета).

**Гарипова З. Профессор Хамид Муштари** // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2013. – № 1-2. – С. 96–99.

**Амиров К.Ф.** Казанских улиц имена / К.Ф.Амиров, Р.Х.Ахметзянова, Р.Г.Вениаминов. – Казань: Центр инновационных технологий, 2008. – 589 с. – Муштари. – С. 332–333.

**Шакирҗанов Р.** Күренешләрне тирәнтен аңлап // Мәшһүр татар галимнәре: мәкаләләр, истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – Б. 157–162.

**Мусабәкова Р.** Хәмит Мөштәри // Кырык татар=Сорок татар=The Forty Tatars / Бөтендөнья язучылар ассоциациясе (Халыкара ПЕН-клуб). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – Б. 216–224.

**Гудкова В.** Профессор Мөштәри һәм аның мәктәбе / тәрҗ. М.Хәмитов // Казан утлары. – 1972. – № 8. – Б. 112–120.

**Хәмит Мөштәри һәм аның иҗаты** // Фән һәм тел. – 1997. – № 1. – Б. 9–12.

**Вәлиева А.** Күренекле татар галимнәре // Мәгариф. – 2001. – № 5. – Б. 55–56.

**Терегулов И.Г.** Илһамлы механик: Хәмит Мөштәри // Казан. – 2001. – № 12. – Б. 24–25.

**Мөштәринең фәнни хезмәтләре исемлеге** // Фән һәм тел. – 1997. – № 1. – Б. 13–15.

## 18 сентября / сентябрь



### Гариф Ахунов

**1925–2000**

**100 лет со дня рождения**
**тууына 100 ел**

Видный писатель и общественный деятель Гариф Ахунов (Гарифзян Ахунзянович Ахунов) родился 18 сентября 1925 года в деревне Учили Арского района Татарской АССР в многодетной крестьянской семье. Учился в школе-семилетке деревни Казанбаш.

После школы начинал самостоятельную трудовую жизнь. Одновременно продолжил образование в Арском педагогическом училище, которое окончил в 1947 году.

В 1947–1952 годах Г.Ахунов – студент историко-филологического факультета Казанского государственного университета. В эти годы начинает заниматься литературным творчеством.

Печататься начал с 1951 года. Первое крупное произведение – повесть «Яшьлек яме» («Красота юности», 1956) – о жизни студенческой молодежи 1950-х годов.

После окончания университета работает в редакции журнала «Совет әдәбияты» («Советская литература»), ныне «Казан утлары».

В 1956 году Гариф Ахунов переезжает жить в город нефтяников – Альметьевск, выступает в печати с очерками, рассказами, маленькими повестями. Здесь он написал роман о жизни нефтяников «Клад» (1963).

В 1968 году Г.Ахунов возвращается в Казань и в 1971–1974 годах работает главным редактором журнала «Казан утлары». В 1974 году его избирают председателем правления Союза писателей Татарстана.

Литературно-творческая деятельность Г.Ахунова разносторонняя: он пишет в разных жанрах. Он – известный прозаик, журналист, публицист, литературный критик, переводчик, автор драматических произведений.

Герои произведений Г.Ахунова – нефтяники, труженики села, руководители производства, представители творческой интеллигенции. Г.Ахунов обращается и к исторической теме.

Как драматург Г.Ахунов известен пьесами «Чулпы җыры» («Звон накосников», 1959 г.; постановка 1959 г.), «Тынгысыз йөрәк» («Бес-

покойное сердце», 1959 г.; постановка 1959 г., соавтор Ф.Мустафин); инсценировкой «Акчарлаклар» («Чайки», постановка 1971 г.) по повести Ш.Камала.

Аналитические статьи Г.Ахунова посвящены литературному процессу; литературные портреты писателей и деятелей искусства опубликованы в республиканских и российских изданиях.

Переводил на татарский язык произведения М.А.Шолохова, А.Н.Островского, А.С.Макаренко, В.А.Закруткина и др.

Повести и рассказы Г.Ахунова переведены на русский, украинский, азербайджанский, узбекский, киргизский, казахский, башкирский, удмуртский, чувашский, марийский, якутский, даргинский и другие языки.

Высоко оценена литературная деятельность писателя. За повесть «Чикләвек төше» («Ядро ореха») и роман «Хәзинә» («Клад») Г.Ахунову присуждена Государственная премия Татарстана им. Г.Тукая, в 1993 году – почётное звание «Народный писатель Республики Татарстан», в 1995 году за роман «Дочь Волги», публицистические статьи последних лет – премия им. Гаяза Исхаки.

Гариф Ахунов умер 4 июня 2000 года в Казани, похоронен в Арске.

Гарифу Ахунову поставлен бронзовый памятник-бюст на Центральной площади Арска на Аллее писателей. Именем писателя названа одна из улиц города в Приволжском районе Казани, в Арске, а также в Альметьевске и Кукморе. Памятная доска была открыта в 2006 году в Альметьевске на д. № 20 по ул. Радищева, где писатель прожил более 10 лет. Мемориальная доска установлена и в Казани на д. № 4А по ул. Новаторов, в котором проживал писатель.

Танылган әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Гариф Ахунов (Гарифҗан Ахунҗан улы Ахунов) 1925 елның 18 сентябрендә Татарстан АССРның Арча районы Өчиле авылында крестьян гаиләсендә туа. Казанбаш авылында җидееллык мәктәптә укый.

Мәктәптән соң мөстәкыйль хезмәт тормышын башлый. Бер үк вакытта Арча педагогика училищесында белем алуын дәвам итә, аны 1947 елда тәмамлый.

1947–1952 елларда Г.Ахунов – Казан дәүләт университетының тарих-филология факультеты студенты. Шушы елларда әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. 1951 елдан әсәрләре басыла. Беренче зур әсәре – «Яшьлек яме» (1956) повесте – 1950 нче еллардагы студент яшьләрнең тормышы турында.

Университетны тәмамлаганнан соң «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясендә эшли.

1956 елда Гариф Ахунов нефтьчеләр шәһәре Әлмәткә күчеп китә, андагы җанлы тормыш материалы нигезендә очерклар, хикәяләр, кечкенә повестьлар яза. Нефтьчеләр тормышы турында «Хәзинә» (1963) һәм «Хуҗалар» (1968) исемле романнарын иҗат итә.

1968 елда Г.Ахунов Казанга кайта һәм 1971–1974 елларда «Казан утлары» журналының баш мөхәррире булып эшли. 1974 елда Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең рәисе итеп сайлана.

Г.Ахуновның әдәби-иҗади эшчәнлеге күпкырлы: төрле жанрларда иҗат итә. Ул – танылган прозаик, журналист, публицист, әдәби тәнкыйтьче, тәрҗемәче, драма әсәрләре авторы.

Г.Ахунов әсәрләре геройлары – нефтьчеләр, авыл хезмәтчәннәре, производство (җитештерү оешмалары) җитәкчеләре, иҗат интел-

лигенциясе вәкилләре. Язучы тарихи темага да мөрәҗәгать иткән.

Драматург буларак, Г.Ахунов «Чулпы җыры» (1959, 1959 елда куелган), «Тынгысыз йөрәк» (1959, 1959 елда куелган; автордашы Ф.Мостафин) пьесалары; Ш.Камал повесте буенча «Акчарлаклар» спектакле (1971 елда куелган) белән таныла.

Г.Ахуновның әдәби процесска багышланган аналитик мәкаләләре, язучыларның һәм сәнгать эшлеклеләренең әдәби портретлары республика һәм Россия басмаларында дөнья күрә.

Ул татар теленә М.А.Шолохов, А.Н.Островский, А.С.Макаренко, В.А.Закруткин һ.б. әсәрләрен тәрҗемә итә.

Г.Ахуновның повестьлары һәм хикәяләре рус, украин, азәрбәйҗан, үзбәк, казакъ, башкорт, удмурт, чуаш, мари, якут, даргин һ.б. телләргә тәрҗемә ителгән.

Язучының әдәби эшчәнлеге югары бәяләнә. «Чикләвек төше» повесте һәм «Хәзинә» романы өчен Г.Ахуновка Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, 1993 елда Татарстан Республикасының халык язучысы дигән мактаулы исем бирелә; 1995 елда «Идел кызы» романы һәм соңгы еллардагы публицистик мәкаләләре өчен Гаяз Исхакый исемендәге премиягә лаек була.

Гариф Ахунов 2000 елның 4 июнендә Казанда вафат була һәм туган ягы Арча зиратына җирләнә.

Гариф Ахуновка Арчаның Үзәк мәйданындагы Язучылар аллеясында бронза һәйкәл-бюст куелган. Язучының исеме Казан шәһәренең Идел буе районындагы, Арчадагы, шулай ук Әлмәттәге һәм Кукмарадагы урамнарга бирелә. 2006 елда Әлмәттә, язучы 10 елдан артык яшәгән Радищев урамындагы 20 нче йортта истәлек тактасы ачыла. Мемориаль такта Казанда язучы яшәгән (Новаторлар урамы, 4А) йортка да куелган.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:

**Ахунов Г.** Клад: роман /пер. с татар. Р.Ахунова. – М.: Современник, 1976. – 463 с.

**Ахунов Г.** Клад: роман /пер. с татар. Р.Ахунова. – 6-е изд. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. – 286 с.

**Ахунов Г.** Дочь Волги: роман / пер. с татар. Р.Ахунова. – 2-е изд. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. – 416 с.

**Ахунов Г.** Увиденное и прожитое Тимерханом: докум. повести / пер. с татар. Б.Хамидуллина. – Казань: Дом печати, 2001. – 232 с.

**Ахунов Г.** Сайланма әсәрләр: 5 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.

Т.1: романнар. – 431 б.

Т.2: романнар. – 383 б.

Т.3: романнар. – 383 б.

Т.4: повестьлар. – 448 б.

Т.5: повестьлар. – 383 б.

**Ахунов Г.** Акча күктән яумый: повестьлар, хикәяләр, очерклар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 288 б.

**Ахунов Г.** Тимерханның күргән-кичергәннәре: докум. повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 351 б.

**Гиниятуллина А.** Писатели Советского Татарстана: биобиблиогр. спр. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 511 с. – Гариф Ахунов. – С. 47–49.

**Абсалямова А.** «Соль земли, правда её и откровение»; Ахунова Н. «В окружении рябин» // Идель. – 2015. – № 9. – С. 48; 49.

**Ахунова Н.** «Гариф Ахунов: писатель, нашедший клад» // Казань. – 2015. – № 10. – С. 119.

**Әдипләребез: биобиблиогр. белешмәлек.** 2 томда. Т. 1 / [төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 735 б. – Гариф Ахунов. – Б. 55–59.

**Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б.** Совет Татарстаны язучылары: биобиблиогр. белешмә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 639 б. – Гариф Ахунов. – Б. 21–26.

**Гариф Ахунов: язучы турында истәлекләр** / төз. Ш.Максудова, Н.Ахунова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 240 б.

**Гариф Ахунов: хәзинәле гомер** / төз. Н.Ахунова, Н.Ганиева. – Казан: Рухият, 2015. – 376 б.

**Надыршина Л.** Гариф Ахунов // Татар әдәбияты тарихы. 8 томда. Т.6: 1960–1980 еллар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – Б. 123–297.

**Мусин Ф.** Гариф Ахунов // Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. Т.6: 60–90 еллар. – Казан: Раннур, 2001. – Б. 141–155.

**Татар драматурглары: биобиблиогр. белешмәлек** /төз. Ф.Ганиева, Р.Яруллина, А.Саттарова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 271 б. – Гариф Ахунов. – Б. 13–14.

**Арсланов М.Г.** Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. – Казан: Заман, 2014. – 584 б. – Ахунов Гариф. – Б. 29–30.

**Галимуллин Ф.** Яңа гасырда да үз кеше // Мәдәни җомга. – 2020. – 30 окт. – Б. 15.

**Хәмидуллин Л.** Иҗади рухлы, ягымлы кеше // Мәдәни җомга. – 2020. – 18 сент. – Б. 11.

**Фәттахов И.** Гариф Ахунов публицистикасы // Мәдәни иомга. – 2016. – 10 июнь. – Б. 9.

**Гайфуллина Ф.** Якты эз калдырган шәхес; **Галиев Ш.** Син калдырган еллар // Безнең мирас. – 2015. – № 10. – Б. 62–63; 65.

## 3 декабря / декабрь



### Салих Сайдашев
### Салих Сәйдәшев

**1900–1954**

**125 лет со дня рождения**
**тууына 125 ел**

Выдающийся композитор Салих Замалетдинович Сайдашев родился 3 декабря 1900 года в Казани. Отец внезапно заболел и умер, так и не увидев сына. Салих воспитывается в семье сестры, муж которой Шигаб Ахмеров принадлежал к прогрессивным кругам татарской интеллигенции.

Музыкальное дарование Салиха проявилось рано. Первым инструментом, на котором он начал играть, была гармоника. Затем родственники купили рояль. Первым его учителем был народный музыкант Загидулла Яруллин, а затем видные педагоги Казанского музыкального училища.

В 1918 году молодой музыкант организует оркестр. В 1919–1920 гг. он добровольцем вступает в ряды Красной Армии, после демобилизации работает в музыкальной школе Оренбурга.

В 1922 году С.Сайдашев возвращается в Казань и в Татарском государственном драматическом театре начинает свою деятельность в качестве дирижёра и музыкального руководителя. В этот период один за другим появляются его музыкальные произведения к драмам: «Галиябану» М.Файзи, «Башмагым» («Башмачки») Х.Ибрагимова, «Ил»

(«Родина»), «Кандыр буенда» («На Кандре»), «Зәңгәр шәл» (Голубая шаль») К.Тинчурина, «Наёмщик» Т.Гиззата и др. Сайдашев создаёт новый жанр, получивший название музыкальной драмы.

В эти же годы он пишет знаменитый «Марш Советской Армии», активно трудится над созданием новых музыкальных произведений в различных жанрах, выступает как пианист и дирижер.

В 1934–1938 гг. С.Сайдашев обучается в Татарской оперной студии при Московской государственной консерватории. Затем возвращается в Татарский государственный академический театр, работает над созданием новых произведений, пишет музыку к спектаклям.

С.Сайдашев умер 16 декабря 1954 года в Москве.

С.Сайдашев признан основоположником татарской профессиональной музыки. Его заслуга состоит в том, что он на подлинно профессиональном и высоком творческом уровне подытожил, обобщил опыт первых народных композиторов, многовековые традиции народа сумел органически соединить с опытом европейской музыки, с фольклором и создать на этой основе подлинно национальное и профессиональное искусство.

Мәшһүр композитор Салих Җамалетдин улы Сәйдәшев 1900 елның 3 декабрендә Казанда туа. Әтисе Салих туганчы ук үлә. Малай күп еллар буе җизнәсе Шиһап Әхмәров гаиләсендә тәрбияләнә. Ул бала чактан ук гармунда уйнарга ярата. Музыкага сәләтен сизгәч, җизнәсе Салихка рояль алып бирә һәм танылган музыкант Заһидулла Яруллинны өенә укытучы итеп чакыра. Соңрак булачак композитор профессиональ музыка укытучыларыннан белем ала.

1918 елда яшь музыкант үзе оркестр оештыра, 1919–1920 елларда үз теләге белән Кызыл Армия сафларында хезмәт итә, аннары Оренбургта музыка мәктәбендә эшли.

1922 елда С.Сәйдәшев Казанга кайта һәм Татар дәүләт драма театрына музыка җитәкчесе һәм дирижёр булып эшкә керә. Сәйдәшевнең композиторлык эшчәнлеге киң колач ала, аның тарафыннан күп драматик әсәрләргә музыка иҗат ителә, осталыгы, профессиональлеге әсәрдән әсәргә камилләшә бара.

Аның тарафыннан М.Фәйзинең «Галиябану», Х.Ибраһимовның «Башмагым», К.Тинчуринның «Ил», «Кандыр буенда», «Зәңгәр шәл», Т.Гыйззәтнең «Наёмщик» һәм башка сәхнә әсәрләренә музыка иҗат ителә. С.Сәйдәшевнең әсәрләре татар театры сәхнәсендә яңа жанр – музыкаль драма жанры барлыкка китерә. Шушы 1920 нче елларда ул үзенең данлыклы «Совет Армиясе маршы»н да яза.

1920–1930 нчы елларда Сәйдәш музыкасы халкыбыз рухи тормышының үзәгендә тора. Аның әсәрләре радиодан, сәхнәләрдән яңгырый. Ул үзе дә еш кына концертларда я пианист, я дирижёр буларак катнаша.

1934–1938 елларда ул Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә укый. Аннан кайткач Татар дәүләт академия театрында эшен дәвам итә, яңа әсәрләр тудыру өстендә эшли.

С.Сәйдәшев 1954 елның 16 декабрендә Мәскәүдә вафат була.

Салих Сәйдәшев – милли профессиональ музыкага, аның барлык төрләренә нигез салучы, милли музыка телен тудыручы, халык рухына, аның табигатенә, моңына тәңгәл килгән музыка чараларын табигый рәвештә дөнья профессиональ музыка казанышлары белән баетучы, берләштерүче; тамашачының

музыкаль фикерләү дәрәҗәсен киңәйтүче һәм киң катлау тамашачыга классик музыканы тыңлауга юл ачучы.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:


**Сәйдәшев С.** Әсәрләр=Сочинения: өч томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000–2004. – На татар. и рус. яз.

Т.1: Музыкаль драмалар (1923–1929). – 2000. – 224 б.

Т.2: Музыкаль драмалар (1932–1953). – 2002. – 232 б.

Т.3: Җырлар, маршлар, инструменталь һәм хореографик әсәрләр, балет (1927–1954) / [ахыр сүз язучы Р.Еникеев]. – 2004. – 239 б.

**Сәйдәшев С.** Без кабызган утлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 310 б.

**Сәйдәшев С.** Зәңгәр шәл: җырлар, арияләр / төз. Х.Әюп; ахыр сүз авт. Й.Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 63 б.

**Салих Сайдашев: материалы и воспоминания** / сост. и авт. вступ. ст., примеч.: С.И.Раимова, З.Ш.Хайруллина. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 127 с.

**Сайдашев А.С.** Отец. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. – 128 с.: ил. – К 110-летию со дня рождения Салиха Сайдашева.

**Саинова-Ахмерова Д.З.** Салих Сайдашев: страницы жизни и творчества композитора. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1999. – 212 с:

**Исхакова-Вамба Р.А.** Салих Сайдашев: очерки и исследования. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. – 79 с.

**Салитова Ф.Ш.** Музыкальные драмы Салиха Сайдашева: (роль жанра в становлении татарской профессиональной музыки). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1988. – 159 с.

**Век Салиха Сайдашева** / М-во культуры РФ; Казан. гос. консерватория. – Казань, 2000. – 132 с. – Библиогр.: С.119–128.

**Нигмедзянов М.** Салих Сайдашев // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. – С. 134–142.

**Сайдашева З.** Салих Сайдашев // Звуковое пространство композиторов Татарстана: очерки. Интевью. Воспомининия. – Казань: Музыка России, 2014. – С. 180–184.

**Шамов С.** Мелодии судьбы народа. – Казань: Изд-во КГУ, 2004. – 153 с.

**Еники А.** Гуляндам: роман / пер. с татар. Р.Кутуя. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1978. – 176 с.

**Еники А.** Повести и рассказы / [пер. с тат. С. Гайнуллиной; авт. предисл. и сост. Г. Гайнуллина]. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2019. – 175 с.: портр.

**Ахмеров Г.** Размышления о феномене Салиха Сайдашева // Идель. – 2001. – № 4. – С. 43–45.

**Бикбулатова И.** Созвездие Сайдашева: (сценарий) / / Мәгариф. – 2000. – № 10. – С. 65–68.

**Гареева Н.** Музыка сердца // Казань. – 2010. – № 12. – С. 57–61. – ил.

**Туманская О.** Одинокий джентльмен в светлом костюме // Татарстан. – Казань. – 2016. – № 1. – С. 66–69.

**Салих Сәйдәшев: фәнни-популяр җыентык** / [фәнни мөх-р Җ. Миңнуллин; төз. Р.Әхмәров, Р.Миңнуллина]. – Казан: Җыен, 2017. – 687 б., [64] б. фоторәс. – (Шәхесләребез = Знаменитые личности). – Библиогр.: б. 670–678.

**Салих Сәйдәшев турында истәлекләр.** – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 159 б.

**Саинова-Әхмәрова Д.** Салих Сәйдәшев: композиторның тормыш һәм иҗат юлы / Ф.Г.Тарханова тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 208 б.: портр., фото б-н.

**Ризванов Г., Әмиров К.** Сәйдәш аланында. – Казан: Идел-Пресс, [2008?]. – 91 б.: фотолар б-н. – Текст татар һәм рус тел.

**Салих Сәйдәшев музее=Музей Салиха Сайдашева** / Татарстанның берләштерелгән дәүләт музее. – Казан, 1995. – 10 б.

**Әтием турында: [Альфред Сәйдәшев истәлекләре]** // Мәдәни җомга. – 2019. – 5 июль. – Б. 18.

**Еники Ә.** Хәтердәге төеннәр: мәкаләләр, очерклар һәм истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 226 б. – Бәхет мәсьәләсе. – Б. 73–81.

**Монасыйпов Ш.** Сәйдәшнең сихри моңы: рухи-фәнни тикшеренүләр тәҗрибәсеннән / / Казан утлары. – 2000. – № 12. – Б. 157–169.

**Хәсәнов М.** Салих Сәйдәшев // Татарстан. – 2000. – № 11. – Б. 16–19.

**Шамов С.** Яшьлекнең ерак таңнары // Казан утлары. – 2007. – № 3. – Б. 142–147.

**Шамов С.** Мәңгелектер Сәйдәш моңнары // Казан утлары. – 2007. – № 5. – Б. 148–152.

**Исәнбәт П.** Авторның кырык елдан соң мәхәббәт аңлатырга җөрьәт итүе; Ильясов Ә. Сәхнә артында эңгерләр: сәхнәнең арткы ягында; Бусыгин Е. Яшьлектә яшьнәдек; Еники Ә. «Вакыт җиле аңа кагылмады. Ул киткәндә актан иде... »; Латыйп К. Мәңгелек моң // Казан. – 1994. – № 3–4. – Б. 39–40, 52–86.

**Еники Ә.** Матурлык: хикәяләр, повестьлар / [төз. һәм кереш сүз авт. Ә. Мотыйгуллина]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 476 б. – Гөләндәм туташ хатирәсе. – Б. 309–478.

